ЯҢА ЗАВОД
Компьютер техникасын хәзер үзебездә җитештерәләр
> 2

ТӨРКИЯДӘН – АВЫЛГА
«Бу аерылу Татарстанның, якын кешеләрнең, үз ризыкларыбызның кадерен белергә өйрәтте»
> 5

УЙНА, ХӘЗРӘТ!
Фәннур хәзрәт халыкка сүз белән дә, эш белән дә булыша, авыл сәхнәсен дә үз итә
> 6

ХА-ХА-ХАНӘ
Булмас, димә, кызык-мызык, фототөрткеләр монда
> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 166–167 (29133–29134) | Сишәмбе | 14 ноябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

АШАСАҢ ДА ТӨШКӘ КЕРӘ

Яшәеш

Кешене тамак йөртә. Соңгы сораштыру мәгълүматларына караганда, илдә яшәүчеләрнең иң зур чыгымнары азык-төлек сатып алуга китә. Юк, тәмлетамаклар саны артмаган. Белгечләр чыгымнар артудан бигрәк, керемнәр кимүен искәртә. Хезмәт хакыннан айлык мәҗбүри чыгымнарны сызып аткач, кесәдә күпме акча кала? «ВТ» хәбәрчесе әнә шуны исәпләп карады.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Акча санарга керешкәнче, чыгымнарны барлап карыйк. Эш табарга ярдәм итүче интернет-порталларның берсе моңа бәйле сораштыру үткәргән. Халыктан: «Айлык акчагызны нәрсәгә тотасыз?» – дип сорашканнар. Баксаң, илдә яшәүчеләрнең яртысы диярлек, тәгаен әйтсәк, 47 проценты хезмәт хакының төп өлешен азык-төлек кибетендә калдыра икән. Болай дип фикер йөртүчеләр Хабаровск краенда (респондентларның 57 проценты шулай дигән), Ярославль һәм Новосибирск өлкәләрендә (һәркайсында 54 процент) күбрәк. Ә менә ашау-эчүгә акчаны иң аз тотучылар Удмуртиядә яши. Күрше республикада яшәүчеләрнең нибары 22 проценты хезмәт хакының күп өлешен азык-төлеккә тотуын әйткән. Бәлки, сер генә бирмиләрдер. Татарстанда яшәүчеләрнең һәр өченчесе диярлек гаилә чыгымнарының төп өлешен ашау-эчүгә киткән акча алуын әйткән.

Икътисад белгече Илдус Сафиуллин сүзләренә караганда, акчаны без түгел, ә инфляция «ашый».

– Бәяләр, шул исәптән азык-төлек хакы да бер урында тормый. Ел азагына кадәр инфляция күрсәткече 7–8 процент дәрәҗәсендә булачак дип көтелә. Шуңа күрә ипи, сөт бәясе үскәнгә дә аптырыйсы юк. Гадәттә, көзге урып-җыю чоры тәмамлангач, кайбер төр продуктларга, мәсәлән, яшелчәгә бәяләр төшүен күзәтә идек. Тик быел анысы да булмады. Статистика мәгълүматларыннан күренгәнчә, бакча саен үскән помидор кибетләрдә сентябрьдән бирле икеләтә диярлек кыйммәтләнгән әнә, – ди белгеч.

Татарстанстат хәбәр итүенчә, октябрь азагында помидордан кала, йомырка, кыяр, чөгендер, алма һәм банан бәясе арткан. Ел ахырына кадәр балык 30 процентка кыйммәтләнәчәк, дип фаразлаучылар да бар. Бәяләрдән тамак туя, билләһи.

Азык-төлектән соң, чыгымнар исемлегенең икенче баскычында – торак, ягъни фатирны арендага алып тору яки ипотека түләүләре. Илдә яшәүчеләрнең 34 проценты әнә шулай дигән. Сүз уңаеннан, Татарстан ил төбәкләре арасында ипотекага торак сатып алу мөмкинлеге күрсәткече буенча кырыгынчы урынга элеккән. Бу хакта «РИА Новости» агентлыгы хәбәр итә. Әйтүләренә караганда, Татарстанда ипотека түләүчеләргә хезмәт хакының яртысын айлык түләүгә тотарга туры килә, банк кредитының уртача күләме исә 3,9 миллион сум тәшкил итә.

Акча янчыгының саллы өлешен тәшкил итүче чыгымнар арасында – торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү, балаларны укыту, төрле түгәрәкләргә йөртү, машинага бензин салу, дару сатып алуны да әйткәннәр. Чыгымнар респондентларның яшенә карап та аерыла. Мәсәлән, яшьләрне күбрәк ипотека йөге борчыса, пенсия яшендәгеләр ут һәм суга түләргә акча җиткерә алмавыннан зарланган.

Казанда яшәүче урта хәлле гаиләнең чыгымнарын без дә исәпләп карадык. Бу эштә безгә шәһәр мәктәпләренең берсендә укытучы булып эшләүче Ландыш Гомәрова ярдәм итте. Ире белән бер ул һәм бер кыз тәрбияли алар.

– Икебезгә 85 мең сум хезмәт хакы алабыз. Яшь гаилә булгач, ипотека да бар, әлбәттә. Казан читендәге өч бүлмәле фатир өчен айлык түләү 40 мең сум тәшкил итә. Бу айда коммуналь хезмәтләр өчен 6,5 мең сум түләргә килгән. Кыш көне ул 11 мең сумга кадәр җитә. Улыбыз түләүле сыйныфта укый. Моның өчен ай саен 2,5 мең сум акча түлибез. Каратэ түгәрәге – айга 2,8 мең сум. Балалар бакчасы өчен 6,5 мең сум түлисе. Кыз бала нәфис булсын дип, бию түгәрәгенә дә йөртәбез. Анысы аена 2 мең сум тора. Гаиләдә бер машина бар. Ягулыкка киткән айлык чыгымнар – 3 мең сум чамасы. Балалар булгач, ашау-эчүгә дә акча күп тотыла. Азык-төлек кибетендә көн саен 500–700 сум калдырам. Кием-салымга, бигрәк тә балаларныкына киткән акчаны санап та торасы юк. Малайларга кышкы куртка гына 5–6 мең сум тора. Эшләгән акчабыз шул айлык мәҗбүри чыгымнарга гына җитә, – ди Ландыш.

Кем әйтмешли, җитә дә, бетә дә.

Фикер

Мария ЕФЛОВА, КФУның Социаль-философия фәннәре һәм массакүләм коммуникацияләр институтының фәнни эшчәнлек буенча директор урынбасары, социология фәннәре докторы:

– Бүген гади халыкның керем дәрәҗәсе үзгәрде. Гомумән, моннан ун ел элек без урта хәлле катлауны социаль статусы ягыннан да, керем дәрәҗәсе буенча да тотрыклы итеп күз алдына китерә идек. Аларның керемнәре, инфляция күрсәткечен исәпкә алып, бүгенгегә караганда югарырак иде. Икътисадый һәм сәяси вазгыять үзгәргән шартларда урта хәлле катлауның чикләре дә юылды. Гади халыкның матди хәлендә дә тотрыклылык кимеде. Бүген гаилә казнасында мәҗбүри чыгымнар өстенлек иткән кешеләр саны артты. Шуңа күрә айлык акчаның зур өлеше ашау-эчү һәм торакка түләүгә китә.

Шимбә сые

Татарстан фермерлары ун ярминкә көнендә барлыгы 789 миллион сумлык азык-төлек саткан. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының матбугат хезмәте хәбәренә караганда, шәһәр халкы җәмгысы 7315 тонна яшелчә, шул исәптән 4528 тонна бәрәңге, 457,3 тонна сөт, 548,8 тонна шикәр комы, 770 тонна ит (443,4 тоннасы – сыер ите) сатып алган.

Ярминкәләрне оештыруда 35 район катнашкан, 9477 берәмлек транспорт җәлеп ителгән.

Көзге ярминкәләр 9 сентябрьдә башланды, 23 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк. Сәүдә һәр шимбә саен Казанда – 14 урында, Чаллы һәм Яшел Үзән районында – 2шәр, Түбән Кама шәһәрендә – 3 урында гөрли. 26 районда исә көзге сәүдә атнаның төрле көннәрендә үткәрелә.

Уңайлы һәм төзек

Быел Казанда сигез иҗтимагый киңлекне (парк-скверлар, җәяүлеләр юллары, яр буйлары һәм башка шундый урыннар) төзекләндерүгә барлыгы 1,4 миллиард сум бирелгән. Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Игорь Куляжев җиткергән мәгълүматларга караганда, Кремль дамбасы буйлап җәяүлеләр һәм велосипедчылар өчен юл салу 337,9 миллион сумга төшкән. Горький исемендәге Үзәк парк «капка»сын төзекләндерүгә бераз гына кимрәк – 331,4 миллион сум тотылган. «Светлая долина» торак комплексы паркының икенче өлешенә 291 миллион сум юлланган. «Балыкчы бакчасы»н яңартуга – 190 миллион, «Хезмәт батырлыгы шәһәре» стеласын төзүгә 130 миллион сум тотылган. Калган объектларны төзекләндерү арзангарак төшкән.

Казан мэры Илсур Метшин сүзләренә караганда, быел гына да Казанда барлыгы 20 гектар мәйданда – төзекләндерү, 8,5 гектар мәйданда реконструкция эшләре башкарылган. «Иҗтимагый киңлекнең һәркайсы тиндәшсез. Без паркта нәрсәләр күрергә теләүләрен шул тирәдә яшәүчеләрнең үзләреннән үк белешәбез», – ди ул.

Уенчык түгел

Исерек хәлдә электр самокатында йөрүчеләргә 30 мең сумга кадәр штраф яный. Моннан тыш самокат яки велосипедта берьюлы берничә кеше утырган өчен дә җәза чаралары әзерләнелә. Федерация Советының Конституцион законнар һәм шәһәр төзелеше комитеты әгъзасы Артем Шейкинның закон проекты Хөкүмәттә хупланган.

Документта шулай ук ЮХИДИ хезмәткәре таләбе белән туктамаган өчен һәм медицина тикшерүеннән баш тарткан өчен җаваплылык каралган. Моның өчен дә штраф күләме 30 меңгә җитәргә мөмкин. Авария булган урынны ташлап китүчеләргә 5 мең сумга кадәр штраф күздә тотылган. Ә инде икәүләшеп йөргән өчен – 3 мең сумга кадәр. Инде килеп, балаларны самокатта утыртып йөрткән өчен 5 мең сумга кадәр штраф салу тәкъдим ителә.

Сәламәтлек

Төчкерү дә җитә

Туберкулез белән авыручылар саны арта. Белгечләр шулай дип чаң суга. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматларына караганда, 2020–2022 еллар аралыгында дөньяда әлеге чирне йоктыручылар саны 500 меңгә арткан. Белгечләр моны пандемия чорында күп кенә чирләргә каршы көрәшкә игътибар киму белән аңлата. Россиядә исә туберкулез йоктыруның тарихи минимумы теркәлгән.

Илнең Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, быел 5 айда 100 мең кешегә туберкулез йоктыруның 274 очрагы туры килгән. Чагыштыру өчен: узган елның шушы чорында 100 мең кешегә шундый 280 очрак туры килгән.

Татарстанда да саннар кимегән. Бер ел эчендә республикада әлеге мәкерле чирне йоктыручылар саны 8,7 процентка кимегән. Республика клиник туберкулезга каршы көрәш диспансерыннан алынган мәгълүматларга караганда, хәзерге вакытта республикада 100 мең кешегә 16,8 туберкулез очрагы туры килә. Узган ел исә шундый 18,4 очрак туры килгән.

Диспансерның баш табиб урынбасары Ленар Әхмәдуллин туберкулез йоктыру очраклары артса да, хәвефләнергә кирәкми, дип тынычландыра. Ник дигәндә, әлеге чирне ачыклау һәм дәвалау ышанычлы контрольдә. Бүген Татарстанда якынча 1,5 мең кеше туберкулездан дәвалана. Чирнең йогышлы формасы белән авыручылар шундук хастаханәгә салына. Авыру йогышлы булудан туктаганчы, шунда дәвалана алар. Аннары табиблар контроле астында ял йортында яки өйдә торып дәваланып бетәләр. Авырып терелүчеләр берничә ел дәвамында диспансерда исәптә тора.

– Туберкулез йоктыру очраклары арту коронавирус пандемиясенә бәйле. Коронавирус, иң беренче чиратта, иммунитетны какшатты. Ә бу, үз чиратында, безнең организмда йокымсырап яткан туберкулез таякчыкларының баш күтәрүенә китерә. Аннары коронавирус белән авырган күп кешенең үпкәләрендә эзләр калды. Бу үзгәрешләр аркасында, үпкәнең сыгылмалылыгы югала, үпкә тукымаларының кан һәм һава әйләнеше начарлана. Андый кешеләрнең туберкулез йоктыру ихтималы арта, – ди табиб. – 2020–2021 еллардагы карантин чорында туберкулезны профилактика чаралары белән алдан ачыклау да кыенлашты. Аннары бу чаралар кабат кире кайтарылды. Бу, үз чиратында, элек күренмәгән авыруларны табарга ярдәм итте.

Әлмәт үзәк район хастаханәсенең табиб-пульмонологы Рөстәм Насретдинов фикеренчә, туберкулез белән шаярырга ярамый.

– Туберкулез һава аша йога. Моның өчен авыру кешенең бер тапкыр төчкерүе дә җитә. Вакытында дәваланмаса, авыру кеше елына уртача 10–15 кешегә зыян салырга мөмкин. Туберкулез йоктырган кеше йөткергәндә, гадәттә, канлы какырык бүленеп чыга. Бу – әлеге чирне башкаларыннан аерып тора торган иң төп билгеләрнең берсе, – ди табиб. – Моннан тыш туберкулез йоктырган кешене хәлсезлек борчый, аның күкрәк читлеге авырта, ул тиз арада ябыга, төнлә тиргә батып уяна, тәнен бизгәк тотарга да мөмкин. Әлеге билгеләрнең берсе генә булса да күзәтелә калса, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Марат ХӨСНУЛЛИН, Россия Хөкүмәте вице-премьеры:

Россиядә 2019 елдан бирле 62,8 мең территория яңартылган. Шуларның 26,4 меңе – иҗтимагый киңлекләр, 36,4 меңе – ишегаллары. Кече шәһәрләрдә һәм тарихи җирлекләрдә уңайлы шәһәр мохите тудыру буенча бөтенроссия бәйгесендә 2018 елдан бирле җиңү яулаган 500 проект тормышка ашырылган. 2030 елда шәһәр тормышы сыйфаты 1,5 мәртәбә артырга тиеш.

(«РИА Новости»)

ТАТАРСТАНДА – БИЗНЕС

FinExpertiza аналитика үзәге белгечләре Татарстанда кече һәм урта бизнес тармагында мәшгульләр санын ачыклаган.

Барлыгы	893,7 мең
Арту күрсәткече	54,6 мең кеше
Үзмәшгульләр	284919

Кара күз

Бу атнада республикада карлы яңгыр, һава температурасы төнлә –7 градуска кадәр төшә.

Гидрометеоүзәк мәгълүматлары буенча, чәршәмбе – 15 ноябрьдә Татарстанның күпчелек өлешендә явым-төшем көтелми. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +2…+5, төнлә 0…+3 градус күрсәтәчәк. Пәнҗешәмбе – 16 ноябрьдә урыны белән карлы яңгыр. Көндез һава температурасы +1…+4 градус чикләрендә тирбәлеп, төнлә +2…–2 градуска кадәр төшәчәк.

Синоптикларның башлангыч фаразына караганда, җомга – 17 ноябрьдә төнлә урыны белән аз гына карлы яңгыр явып үтәчәк. Һава температурасы +2…–3. Шимбә – 18 ноябрьдә көндез 0…+5, төнлә –2…–7 градус. Юлларда бозлавык булырга мөмкин.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ТАБЫШСЫЗ КАЛЫШ

АКШ армиясе полковнигы Дуглас Макгрегор (Трампның элекке киңәшчесе) глобализм тарафдарларының зур финанс җимерелүе планлаштыруларын хәбәр итеп: «2024 ел сайлаулары булмаячак», – дип белдерде.

Аның фикеренчә, озакламый, көтмәгәндә, Американың барлык эре банклары ябылачак. Ябылу өч атна дәвам итәчәк. Бу үз чиратында бөтендөнья финанс кризисына китерәчәк. Байден администрациясе хәрби хәл кертәчәк. Дугласның белдерүен конспирология теориясе кысасында карарга кирәк. Конспирологлар гадәттә вакыйгаларны гадәттән тыш куертып фаразлый, алар әйткәннәр тормышка аша дигән сүз түгел. Әмма дөнья икътисады глобаль кризисның бусагасын үтте инде. Көтелмәгән хәлләр, чынлап та, булырга һәм фаразлардан да куркынычрак булырга мөмкин. Бүген дөньяда барган чәчләрне үрә торгызырлык вәхши конфликтларны алдан фаразлаучыларга без, мәсәлән, ышанмас идек.

Фактлар дөнья икътисадында хәлләрнең шәп булмавын дәлилли. Якын Көнчыгышта зур конфликт куркынычы дәвам итүгә карамастан, үткән атнада нефтькә бәяләр төште. «Брент» 80 доллардан түбәнрәк йөри башлады. Арзанаюның «кара алтын» чыгаруны нык киметү фонында баруы ихтыяҗның кимүен күрсәтә. Үткән атнада япон банкларының акцияләре очсызланды. Япон икътисады кысылу нәтиҗәсендә дөньяның өченче икътисады ролен Германия үти башлаячак дигән хәбәрләр бар. Искәртик: Германиядә рецессия башлану рәсми рәвештә танылды. Димәк, японнарда эшләр тагын да начаррак.

Дөньяның әйдәп баручы сәнәгать компанияләренең табышлары быелның июль – сентябрь айларында үткән елның өченче кварталы белән чагыштырганда 9 процентка кимегән. Япон газетасы «Никкэй» глобаль индустриянең табышы дүртенче квартал рәттән кимү турында хәбәр итә. Нәтиҗәне япон белгечләре бригадасы ясаган. Алар АКШ, Евросоюз, Япония һәм Кытайның 13 мең компаниясе күрсәткечләрен тикшергән. Химия сәнәгатендә табыш өченче кварталда – 43 процентка, электрон техника җитештерүчеләрдә – 12, станок төзелешендә 10 процентка кимегән. Әмма сәнәгатькә карамаган тармакларда табыш 16 процентка үскән. Болар – ресторannar, күңел ачу индустриясе, туризм һәм шуларга якын башка тармаклар. Аларда табыш артуны аңлап була, чөнки алдагы елларда ковидка бәйле рәвештә бөтенләй диярлек эштән туктаганнар иде. Бу җәһәттән караганда 16 процент үсеш бик әллә нәрсә түгел. Анализ шуны күрсәтә: Кытайга бәйле бизнес табышын югалта. Бу Күк асты илендәге проблемаларның бөтен планетага җәелә баруын раслый.

Россиядә

ӨЙДӘГЕ БУРАН

Рәсми статистиканың «Россия икътисады үсештә» дигән хәбәрен укып шатланырга өлгермисең, финансчылардан кара хәбәрләр ява башлый. Инфляция көчәя, давылга әйләнеп бара, диләр.

Кибеттән ипи белән шикәр генә алган кешегә бәяләр күтәрелеше бик сизелмәскә мөмкин, әмма ассортиментны киңәйтүгә, акча янчыгында искән җил, чынлап та, көзгә давыл булып күренә. Белгечләр бездәге сөт һәм май, сыр бәясе АКШтагыдан аерылмый, диләр. Океан артында да соңгы кырык елда рекордлы инфляция баруын истә тотыйк. Аларда эремчек һәм йогырт бездәгедән 1,5 тапкыр кыйммәтрәк икән. Йомырка һәм каймак та 30 процентка кыйбатрак йөри. Бездә бәрәңге, кишер һәм суган күпкә арзан. Башка позицияләрдә бәяләр Америка һәм Европа бәяләренә якынлаша, диләр.

Инфляция котыруын Үзәк банк рәисе Эльвира Нәбиуллина да яшерми. 9 ноябрьдә ул Дәүләт Думасының Финанс сәясәте, бюджет һәм салымнар, Икътисад сәясәте комитетларының берләштерелгән утырышында катнашты һәм 2023 ел ахырына кадәр төп ставканы тагын бер күтәрергә кирәк булачагын әйтте. Аның фикеренчә, икътисад бөтен ресурсларны файдаланып бетерде, ул үссен өчен, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрергә кирәк.

Нәбиулина позициясен болайрак аңларга була. Процент ставкасы түбән булганда, бизнес күпләп кредит ала да эшкә тота, әмма мәгълүм сәбәпләр аркасында, кредитлар җитештерүнең артуына китерми, ихтыяҗны арттырып, бәяләрне генә үстерә. Бу төзелеш тармагында яхшы күренә. Торак бәяләре болытларны узып китте инде, төзелеш материалларына бәяләр дә чиксез кыйммәтләнде. Эш шуңа барып җитте: ипотека алучыларның 47 проценты керемнәренең 80 проценттан артыграгын бурыч түләргә тотарга мәҗбүр. Быелның беренче яртыеллыгында бирелгән ипотека кредитларының 39 процентын бурычлылар 65 яшьтән соң түләп бетерергә тиеш. Ул яшьтә аларның керемнәре буламы-юкмы бит әле.

Үзәк банк ажиотажны басуның бер генә юлын белә: ставканы күтәрә. Нәтиҗәдә октябрьдә ипотека базары 20 процентка кимегән. Кимүдә беренче взнослар күләмен күтәрү дә үз сүзен әйтә. Икенчел торакка ихтыяҗ 30–45 процентка кимеде дигән сүзләр бар.

Росстатның иң соңгы хәбәрләре ноябрьдә бәяләр үсеше тизләнүен әйтә. Җиде көн эчендә үсеш уртача 0,37 процент икән. Моны рекордка якын инфляция дип әйтәләр. 2022 елда ноябрь ае буенча күтәрелеш шундый булган.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ҮЗЕБЕЗ ӨЧЕН ҮЗЕБЕЗДӘ

ЛАЕШ РАЙОНЫНДА КОМПЬЮТЕР ТЕХНИКАСЫ ҖИТЕШТЕРҮ БУЕНЧА ЗАВОД ЭШЛИ БАШЛАДЫ

2 млрд сум инвестиция, 400ләп эшче, елына 300 мең эшләнмә. Лаеш районында ICL компаниясенең компьютер техникасы һәм система платасын (материнская плата) җитештерү заводы ачылды.

tatarstan.ru

Яңа заводны эшләтеп җибәрүдә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов шәхсән катнашты.

– Бу – илебезнең IT тармактагы бәйсезлеген тәэмин итү проекты, – диде Рәис ачылыш тантанасында. Әлеге проект «Иннополис» махсус икътисадый зонасы һәм Россия сәнәгать үсеше фонды теләктәшлеге белән чынга ашырылган.

Рәис сүзләрендә хаклык бар. 8 мең квадрат метр мәйданны алып торган әлеге завод җитештерү куәтен кыска вакытта арттыру, күләмле заказларны тиз арада башкару һәм җитештерү вакытын киметүгә сәбәпче булачак. Импортка алмаш табу турында аеруча еш сөйләгән чорда бу бигрәк тә актуаль.

– Яңа завод ачылу Россиянең радиоэлектроника сәнәгате өчен мөһим вакыйга булып тора. Илнең бу тармактагы мөстәкыйльлеген һәм импортны алмаштыруны тәэмин итү ихтыяҗы булган шартларда, мондый җитештерү үзәкләрен булдыру стратегик бурыч санала, – диде республиканың Премьер-министр урынбасары Роман Шәйхетдинов.

Сервер, мәгълүмат саклау системалары, компьютер – заводта барлыгы 200дән артык төр исәпләү техникасы чыгару планлаштырыла. Яңа предприятиедә Intel, «Байкал», «Эльбрус», AMD процессорларын урнаштыру белән берлектә система платаларын җитештерү каралган. Беренче этапта 300 мең эшләнмә җитештерү нияте булса, соңрак бу санны 1 миллионга кадәр җиткерергә исәп. Бу исә үз чиратында компаниягә плата базарының 9 процентын алып, импортны өлешчә алмаштырырга мөмкинлек бирәчәк.

Сан гына түгел, эчтәлек тә мөһим. Россиянең сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Василий Шпакның ICL компаниясенә теләге – технологик яктан да үсәргә.

– Тирәнрәк эшләп, технологик чылбырны тагын да киңәйтеп, яңа эш урыннары булдырып эшләвегезне телим, – диде ул.

Соңрак Рәис катнашында киңәшмә узды.

– Үз вакытында без «Иннополис» махсус зонасы буенча дөрес карар кабул иттек дип уйлыйм. Югары Ослан районындагы мәйданчыкта университет һәм технопарклар тупланган, ә монда – җитештерү. «Лаеш» индустриаль паркы Казан һәм аэропорт янында урнашкан. Кирәкле инфраструктура җайга салынган. Болар барысы да көндәшлеккә сәләтебезне арттыра, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Фикер

Айрат ХӘЙРУЛЛИН, Татарстан дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры:
– Планнар чынга аша. Лаешта ICL компаниясенең яңа заводы ачылды. Төзелеш эшләре былтыр ук башланган иде инде. Компания кыска вакыт эчендә заводны эшләтеп җибәрүгә иреште. Цехларда эш бара.

(«Телеграм»дагы сәхифәсеннән)

Тарих та санлаша

Киләчәктә архив эшендә ясалма интеллекттан файдаланмакчылар. Аудиовизуаль документлар өчен дә «оя» булдырасы иде. Дәүләт архивы әнә шуларга өметләнә.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Лаеш районының Столбище бистәсендәге Дәүләт архивы эшчәнлеге белән танышып кайтты. Архив эше буенча комитет рәисе Гөлнара Габдрахманова аңа яңа бинага күченгәннән соң булган яңалыкларны сөйләде.

Билгеле булганча, архивның яңа урынга күченүе былтыр төгәлләнде. Биредә кәгазь һәм аудиовизуаль документларны саклау өчен барлык шартлар да бар.

Гөлнара Габдрахманова архив гамәлгә ашыра торган проектлар турында да әйтте. Аерым алганда, болар – электрон рәвештә эксперт-тикшерү комиссиясен үткәрү, халыктан килә торган мөрәҗәгатьләр белән эшләү (сүз уңаеннан, елына 44 меңләп мөрәҗәгать кабул итәләр), документларны яңарту. Моннан тыш «Татармультфильм» берләшмәсе белән берлектә балалар өчен «Истәлек» белем бирү проектын тормышка ашыралар.

Хәзерге вакытта архивларда саклanучы мирас күләме буенча Татарстан Идел буе федераль округында икенче урында тора. Сан теле белән әйтсәк, 5 млн 993 мең берәмлек документ бу.

Киләчәк димәктән, Гөлнара Габдрахманова архив эшенә ясалма интеллектны актив кертү һәм аудиовизуаль документлар өчен архив булдыру турында ниятләре белән уртаклашты.

СЫЙФАТ БӘЯСЕ

Борчыган мәсьәлә

Кибет киштәләренә куелган социаль әһәмияткә ия товарларның 21 проценты тиешле таләпләргә җавап бирми. Болар бигрәк тә – сөт һәм сөт ризыклары, икмәк, балык, ит... Без нинди ризык ашыйбыз? Арзанлы ризык сыйфатлы була аламы? Көнкүреш техникасын алганда нәрсәләргә игътибар итәргә?

Бу хакта журналистлар белән очрашуда Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясенең эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлеге җитәкчесе Розалия Арсланова сөйләде:

– Җитештерүчеләр елдан-ел «остара». Әйтик, без тикшерүләр вакытында моңа кадәр очрамаган ферментларны ачыкладык. Алар организмга зур зыян да салмаска мөмкин, ләкин кыйммәтле ингредиентлар урынына арзанлысын куллануны яшереп калдырырга сәләтле.

Гомумән, белгечләр продуктларның сыйфаты елдан-ел начарлануын белдерә. Тикшерүләр дә шуны ук раслый.

– Фальсификатларның саны кимеми, сырлар буенча вазгыять аеруча катлаулы. Күпчелегендә үсемлек майлары табыла. Аларның күбесе чит төбәкләрдә, Мәскәүдә җитештерелгән. Кызганыч, халык товарларны бәясенә карап ала. Ләкин сыйфатлы продукция арзан була алмый. Ә халык арзанлыны сатып алырга тырыша. Шул сәбәпле яхшы товар сатыла алмыйча бозыла, – дип саный Розалия Арсланова.

Аның сүзләренчә, быел республикага алып керелгән алкогольле продукциянең күләме 4 процентка арткан. Аларның һәркайсы бик җитди контроль уза. Тикшерү вакытында шуларның 3 процентының брак икәнлеге ачыкланган.

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Юлия Булатова исә тугыз ай эчендә эшмәкәрләрнең эшчәнлегенә бәйле мөрәҗәгатьләр саны артуын әйтте. 2 меңнән артык кисәтү ясалган. Бу – узган елның шушы чоры белән чагыштырганда, 16 процентка күбрәк дигән сүз.

– Идарәгә кабул ителгән мөрәҗәгатьләрнең 45 проценты кулланучылар хокукын яклау буенча. Мөрәҗәгатьләрнең якынча 40 проценты товарларның сыйфатына бәйле, – ди ул.

Кешеләр товарларның сыйфатын «Честный знак» мобиль кушымтасы ярдәмендә дә тикшерә ала. Моның өчен аны телефонга урнаштырырга һәм товарның кодын күчереп алырга кирәк. Код буенча теге яки бу товарны кем сатуын, кем эшләгәнен, кыскасы, барлык мәгълүматны ачыкларга мөмкин. Бу ысул белән җиңел сәнәгать товарларын, аяк киемнәрен, тәгәрмәчләрне, хушбуй, чын мехтан эшләнгән товарларны, сөт һәм сөт ризыкларын, шешәләргә тутырылган суны тикшереп була. Теге яки бу җитешсезлекләр ачыкланган очракта, кешеләр шушы ук кушымтада үзләренең мөрәҗәгатьләрен дә калдыра ала.

– Быел 9 ай эчендә 24 мөрәҗәгать кабул иттек. Без аларның барысын да карадык һәм тиешле кешеләргә кисәтүләр ясадык. Билгеле, бу алай ук зур саннар түгел, чөнки күпләр әлеге кушымта турында белми, белсә дә файдаланмый, – диде Юлия Булатова.

Гомумән алганда, тугыз ай эчендә меңнән артык эш судка кадәр барып җиткән, аларның 90 проценты кулланучы файдасына хәл ителгән.

– Узган ел һәм быел кулланучылар «Золотое яблоко» оешмасының бүләк итеп бирә торган сертификатларын куллану шартларыннан канәгать булмауларын әйтте. Кулланучылар, вакыты чыгу сәбәпле, әлеге сертификатларны я кулланырга өлгерми, я акчаларын кайтара алмый кала иде. Берничә тапкыр кисәтүгә карамастан, сатучы битарафлык күрсәтте. Һәм берничә кешене судка биреп, аны оттык. Аның нәтиҗәсе буларак, килешүгә үзгәрешләр кертелде. Шуңа күрә әгәр әлеге оешманың гамәлләреннән зыян күрүчеләр бар икән, сатучыга мөрәҗәгать итә ала, – дип аңлатты Юлия Булатова.

Белгеч көнкүреш һәм компьютер техникасын төзекләндерүчеләр өстеннән дә шикаятьләрнең күп килүен әйтте.

– Гадәттә мондый үзәкләрдә кулланучыларга бушлай диагностика ясарга һәм ватылган техниканы төзәтергә вәгъдә бирәләр. Шул ук вакытта бернинди дә язмача килешүләр төзелми. Менә моңа аеруча игътибарлы булырга кирәк. Көнкүреш техникасын ремонтка биргәннән соң берничә көн узгач, остаханә яки сервис үзәгенең намуссыз хезмәткәрләре шалтыратып, ремонт өчен зур күләмдә акча түләргә кирәклеген әйтә. Безгә мөрәҗәгать итүчеләрнең сүзләреннән аңлашылганча, түлисе акча хәтта товар бәясеннән 80 процентка кыйммәтрәк булырга мөмкин. Билгеле, ике арада аңлашылмаучылык килеп чыга. Төзәтүче төрле ысуллар белән акча алырга тырыша. Тагын бер тапкыр кисәтәм: эш башланганчы, килешү төзелергә тиеш, – диде Юлия Булатова.

Ярык тагарак алдында калмас өчен, хезмәт күрсәтү үзәгенә барганчы, интернеттан башка кулланучыларның фикерләрен белешү дә зыян итмәс. Моннан тыш, кулланучы төзәтү эшләре башланганчы акчаны тулысынча түләп куярга ашыкмасын иде. Теләге бар икән, ярты хакын гына да түләп тора ала.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

КАДЕРЛЕ КАДР

Башкаладагы 2 нче татар гимназиясе янәшәсендә «Остазлык мәктәбе» төзиләр. Нинди мәктәп ул? Кайсы ягы белән аерылып торачак? Бу хакта гимназия директоры Рамил Гайнуллин белән сөйләштек.

«Остазлык мәктәбе» проекты 2018 елда ук булдырылган. Әмма вазгыять үзгәрү сәбәпле, төзелеш башланып китә алмаган.

– Бу мәсьәләне күп мәртәбә күтәреп чыктык. Ниһаять, эш кузгалды. Республика тарафыннан акча бүлеп бирелде. Моның өчен Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка, ТР Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтовка, республика мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллинга рәхмәт. Аларның ярдәме белән проектны тормышка ашырачакбыз. Яңа елга кадәр төзелеш башланыр дип көтәбез. Киләсе уку елына ачарга исәп, – дип сөйләде Рамил Гайнуллин.

Аның әйтүенчә, мондый мәктәпләр республикада юк. Илдә дә бармы икән? «Остазлык мәктәбе» 2 нче татар гимназиясенең фәннәрне татар телендә укыту тәҗрибәсен милли мәктәпләргә өйрәтүне күздә тота. Ул булачак укытучы – студентларга практика лабораториясе ролен дә үтәячәк. Шулай ук яңа бина гимназиядә укучылар санын арттыру мөмкинлеген дә бирәчәк.

– Татар мәктәбе директоры буларак шуны әйтә алам: бүген фәннәрне туган телдә укытучы мөгаллимнәрне табу бик авыр. Гимназиядә кадрлар җитә, әмма киләчәктә кытлык туачак. Без бит үзебезнең гимназия генә түгел, башка мәктәпләр турында да уйлыйбыз. Кадрлар мәсьәләсе кискен тора, моны яшерергә ярамый, – дип, әлеге идеянең ничек тууын аңлатты директор. – Бу базада фәннәрне ана телендә алып бара торган уку йортлары өчен белгечләр әзерләнәчәк. КФУ, Татарстан Мәгарифне үстерү институты галимнәре, методистлар белән дә эшләргә җыенабыз.

Билгеле, бу урында «Республикадагы педагогик вузлар, көллиятләр генә җитмимени, алар үз бурычын үтәмимени?» дигән сорау да туа. Рамил Гайнулин белдергәнчә, алар җитә һәм үз эшен яхшы башкара. Әмма булачак белгечләрне мәктәп мохитенә кертеп җибәрү җайлы түгел. Вуз тәмамлаган студент белән яшь белгеч арасында аерма зур. Менә шул аерманы бетерергә кирәк. Булачак укытучылар «ачык» дәресләргә керәчәк, психологик яктан балалар белән эшләргә өйрәнәчәк. Кыскасы, өзлексез практика көтелә.

«Остазлык мәктәбе» заманча җиһазландырылган яңа бинада эшләячәк. 400ләп бала укыр дип көтелә. Анда заманча укыту кабинетлары, алдынгы инженерлык юнәлешләре буенча төрле җиһазлар, ноутбук, робот техникасы базалары, белем һәм тәрбия лабораторияләре урнашачак.

Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк. Казандагы 2 нче гимназия – республикакүләм чараларны иң күп уздыра торган мәктәпләрнең берсе. «Остазлык мәктәбе»нең бинасы әле төзелмәгән булса да, шул исемдәге проектны башлап җибәргәннәр. Айга бер мәртәбә узучы семинарларда милли мәктәп укытучылары, җитәкчеләрен гимназия эшчәнлеге, аның традицияләре, тәҗрибәсе, яңа проектлар белән таныштырачаклар. Гимназиядә «Татарча онлайн мәктәп» проекты тормышка ашырыла. Тиздән «Остаз» дигән мобиль кушымта булдырылачак. Анда мәктәп программасы буенча төрле фәннәрдән интерактив биремнәр тәкъдим ителәчәк.

Сәрия МИФТАХОВА

ВОЛОНТЕР ЕЛЕНА

Гыйбрәт

Бер елдан артык инде ул башка дөньяда яши. Төгәлрәге, башка гамьнәр белән. Башкалар кебек, тыныч кына пенсиясен алып, балалары, оныклары өчен сөенеп, тыныч, тигез картлыкка шөкер итеп кенә яшисе дә...

Хәер, шөкер итә ул, бу сүзне хәзер элеккегә караганда да күбрәк, ешрак әйтә кебек. Чагыштырып карар мөмкинлекләре күп ләбаса. Моның өчен – тормышның, яшәүнең кадерен аңлар өчен – хәрби бәрелешләр барган якларга бер генә тапкыр барып кайту да җитә, ди язмамның герое Елена Вәлиева. Үзе инде дүртенче тапкыр шул сәфәргә әзерләнә.

Барысы да үткән елның сентябреннән башлана. Социаль челтәрдә махсус хәрби операциядә булганнарга ярдәм оештыручы төркем барлыгын белеп, Елена ханым шунда кушыла. Солдатларга, госпитальдә ятучыларга кипкән җиләк-җимешләр кирәклеге турында язма аның бөтен күңелен айкый: кибеткә барып, күп итеп цитруслар сатып ала, махсус киптергечтә киптерә. Аларны илтеп тапшыру өчен, әлеге төркемне оештыручы Гөлчәчәк Усинова, волонтер егетләр Рамил Әгълиуллин, Айдар Хисмәтуллин белән таныша. Бу сөйләшүләрдән ул шулкадәр канатланып кайта ки, бер ай эчендә хәрби операциядәгеләргә, госпитальләргә, җирле халыкка, ятим балаларга дип, ике тонна кирәк-ярак җыйнап, илтеп тапшыра. Бу аз да түгел, күп тә түгел, 172 капчык, 321 тартма әйбер була! Бер шул дөньяга килеп эләккәч, ул бу гамәлләрдән башка яши дә алмый башлый. Авыл төркеменә, дусларына, танышларына хәбәр сала. Башта аны белүчеләр, аннан инде, ышанычлы кешегә әйләнгәнен күреп, бер белмәгән кешеләр дә аның капкасын шакый. Ул исә барысын да, күз яшьләре белән рәхмәтләр әйтеп, озатып кала, бөтенесен язып теркәп бара, көндезләрен өйдәге бөтен эшен читкә куеп, кешеләр кабул итсә, кичләрен шуларны тәртипләп, аралап, җибәрергә әзерләп куя, аннан районлагыларга, хәтта Казанда оештырылган ярдәм пунктларына да илтеп тапшыра. Берничә айдан соң Елена апа күбрәк ятим балаларга кирәк-ярак җыйнау белән мавыгып китә. Моның сәбәбе шактый тирәндә була, аны якыннары гына белә.

Ул – ерак Казахстанда туган, дүрт яшендә 28 яшьлек әнисен, аннан бераздан фаҗигале үлем белән әтисен дә югалтып, ятимнәр йортының ни икәнен ишетеп, укып түгел, сабый иңнәрендә күтәргән кеше. Бераздан аны Балтач районының Яңгул балалар йортына күчерәләр. Шул чакта абыйсы Валерий белән юллары аерыла. Кызганыч, бер елдан Яңгулдагы балалар йорты ябыла. Еленаның әтисе шушы районның Биктәш авылыннан була. Ятимә кызны өлкән яшьтәге әби-бабасы үз карамагына ала. Бар яктан уңган-булган, мөстәкыйль булып үскән Елена аларга бер авырлык китерми, киресенчә, картлыкларында кадер-хөрмәт күрсәтә. Абыйсы Валерий белән унсигез ел үткәч кенә табыша, әмма башка югалтышмый инде алар. Бүген гаиләсе белән Свердловск каласында яшәүче абыйсы белән элемтәләре бик нык. «Балалар йортында үссә дә, ул искиткеч яхшы кеше булып үскән», – дип сөенә Елена ханым.

Башта җыйган әйберләрен башкалар аша җибәрүче Елена ханым быел март аенда, ә нигә әле үз кулларым белән илтеп бирмәскә, ди һәм ерак юлга кузгала. Аннан тагын, тагын... Изге эштә теләктәшләр күп табыла. «Эшмәкәрләр Сергей Мошкин, Марат Галәветдинов, Ирина, Гөлнара, Гөлфия, Рания, Рафил, Илшат, Руслан... – дип саный героем. – Күпме тапкан малларын шушы изге эшкә тоттылар һәм тоталар, кем – хезмәте, кем техникасы белән һәрчак ярдәмгә килергә әзер тора. Мин аларга бөтен күңелем белән сокланам һәм бик рәхмәтлемен...»

– Бу көннәрдә «ВК»дагы битегезгә Казандагы балалар йортына баруыгыз турында фото куйдыгыз.

– Казандагы әлеге балалар йортына беренче баруым. 16 ел шушы балалар йортына ярдәм күрсәтүче райондашым Ринат Нәбиев белән бергә бардык. Бер тонна бәрәңге, яшелчә, киемнәр, тәмлүшкәләр илттек. Луганскидагы мин бара торган балалар йортында бөтенесе – хәрби хәрәкәтләр нәтиҗәсендә ятим калган балалар, ә Казандагысында әти-әниле, ташланган балалар күп. Аерма шунда булса да, алар барысы да – балалар. Инде Луганскидагылары белән дуслашып беттек. Алар мине көтеп торалар. Мин дә өйгә кайтып җиткәнче аларны сагына башлыйм. Бер генә шофер белән барганда, биш көннән әйләнеп кайтабыз, ике шофер белән барсак, өч көндә өйдә булабыз. Сәфәргә төрле уйлар белән чыгасың, кайтканда исә хисләр бөтенләй тулыша. Өйгә кайткач, мин ун көн беркем белән сөйләшмим, үз-үземә бикләнәм. Аннан тагын әйберләр туплауга керешәм, бу шөгыль миңа күңел тынычлыгы бирә. Бу көннәрдә тагын әйберләр җыя башладым. Яңа елга кадәр барып, сабыйларны сөендерәсе килә. Бу юлы исәбем – Луганскидагы хәрби госпитальгә дә керү, шуңа күрә аларга да кирәкле әйберләр җыябыз...

Елена – безнең авыл килене. Күрше авыл кызы. Өч дистә елдан артык инде бездән ерак түгел Норма авылында яшиләр. Газинур абый белән үзләре кебек тырыш бер ул, бер кыз үстерделәр, балалары икесе дә гаиләле, үзләре әти-әниләр. Якыннары аңламаса, Елена апа елдан артык инде волонтерлык белән шөгыльләнә дә алмас иде. Әмма без аның бик тә максатчан булуын, райондагы данлыклы мех әйберләр фабрикасында мактаулы мастер булган елларын да әйбәт беләбез.Тормыш сынаулары чыныктырган, әмма сабый чактан күңеленә шәфкатьлелек орлыгы салган кеше башкача яши дә алмыйдыр...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

- РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
- ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
- ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНҮ, ДӘВАЛАНУ ҺӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
- ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ ҺӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ
- 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
- ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ ҺӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
- КРЕДИТ ҺӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
- БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
- БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
- КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР ҺӘМ ГАРАНТИЯЛӘР

ЯКТЫ ЭЗЕ КАЛДЫ

Республикабыз җәмәгатьчелеге Фатыйх Сибагатуллинны искә алды. Легендар шәхесебезнең бакыйлыкка күчүенә елдан артты, чаралар Арча төбәгендәге Апаз авылында үтте. Җомга көн иде, җиңелчә генә яңгыр сибәләп торды. Халыкның исәбе-хисабы юк: авылдашлары – апазлылар, тирә-күрше авыллардан килүчеләр, Дәүләт Советы депутатлары, галимнәр, хакимият башлыклары, туганнары, хезмәттәшләре, фикердәшләре, мәктәп укучылары һ.б.

Искә алу чарасы Апаз зиратында Фатыйх Сибагатуллин каберенә һәйкәл урнаштыру белән башланды. Мәрхүмнең әти-әнисе, туганнары, улы Фәрит тә шушы зиратта җирләнгән, һәйкәлгә чәчәкләр куелды, мәрхүм рухына дога укылды, аннан чара авыл мәдәният йортында дәвам итте. Анда шәхесебезнең тормышына, яшәешенә, тарихны барлаудагы иҗатына мөнәсәбәтле күргәзмә оештырылган иде, җыелган халык истәлекләр белән уртаклашты, искә алу чарасы үзешчәннәр чыгышы – тирән мәгънәле җырлар белән аралашып барды.

– Фатыйх абый шәхесенә бәрәү дә битараф түгел, ул үзе дә янәшә-тирәдәгеләргә бик игътибарлы булды, дәрәҗәле вазыйфаларда эшләсә дә, халыктан аерылмады, – диде Татарстан Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров. – Бүгенге һава торышының аның эш-гамәлләренә туры килүенә дә игътибар итегез әле: туган туфрак дымга туена, Фатыйх абый да халкыбызны муллыкта яшәтү өчен тырышлыгын кызганмады.

– Фатыйх әфәнде турында сүз чыкса: «Аңа агы – ак, карасы – кара», – дигән әйтем гадәткә кергән иде. Ул ялагайлануны белмәде, күңелендә ни бар, шуны ачык, аңлаешлы итеп әйтеп бирә, аңлата алды, хезмәтендә менә шул ачык чагылды. Ул һәрвакыт яңалыкка омтылды, авыл хуҗалыгы тармагын үзгәртеп корды, – дип, «Татарстан муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе Әгъзам Гобәйдуллин хәтер яңартты. – Минем аның белән бергә эшләгән чакларым да, җитәкчелек дилбегәсен аның миңа тапшырган вакытлары да булды, үзара аңлашып, ярдәмләшеп хезмәт иттек. Мин шуның белән бәхетле һәм минем кебек бәхетлеләр, аңа рәхмәтлеләр бихисап, аның кебек шәхесләр һич кенә дә онытылырга тиеш түгел.

– Без аннан бераз өлкәнрәк булсак та, ул безнең өчен остаз да булды, җитәкчелек итү серләренә дә төшендерде, янәшә-тирәдәгеләргә һәрдаим игътибарлы булуны таләп итте. – Монысы республика агросәнәгате ветераннары Советы җитәкчесе Марс Алиев сүзләре. – Аның республика агросәнәгате үсешенә керткән өлеше әйтеп-сөйләп кенә бетерерлек түгел. Бездәге яңалыкларны башка төбәкләрдән дә килеп өйрәнәләр иде.

Татарстан Дәүләт Советы депутатлары Таһир Һадиев, Камил Нугаев, Лотфулла Шәфигуллин, Әтнә районы хакимияте башлыгы Габделәхәт Хәкимов, Балтач районы хакимияте башлыгы Рамил Нотфуллин, Нурлат районы хакимияте башлыгы Дамир Ишкинеев, Казан дәүләт ветеринария академиясе ректоры Рөстәм Равилов, заманында аңа ветеринария академиясендә белем биргән, бүген дә шул вазыйфада булып, хәзер туксан яшен тутырып килүче галим Иван Никитин һәм башкалар легендар шәхесебезне үрнәк зат буларак сагынып, юксынып искә алдылар.

Фатыйх Сибагатуллин – Россиянең һәм Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, ветеринария фәннәре докторы, күпсанлы фәнни хезмәтләр, тарихи китаплар авторы. Заманында КПССның Балтач район комитетында икенче секретарь, Арча районы башкарма комитеты җитәкчесе, КПССның Мамадыш район комитеты беренче секретаре була, туксанынчы еллар башында Татарстан Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры вазыйфасында хезмәт куя, 1996–2007 елларда Нурлат районы хакимияте башлыгы, аннан – Россия Дәүләт Думасы депутаты.

Габделбәр РИЗВАНОВ

arskmedia.ru

Илшат НУРИЕВ, Арча муниципаль районы башлыгы:
– Фатыйх әфәнде белән без – авылдашлар. Олы йөрәкле, киң күңелле шәхес иде ул. Апаз халкы өчен башкарган игелекләренә авылдашларыбыз бик рәхмәтле. Очрашканда авылның бер очыннан икенчесенә кадәр хәтер яңарта торган гадәтебез дә бар иде. Вакыт-вакыт искә төшерә алмыйча азапланган мизгелләрдә ул: «Бу хәл безне бизәми, йә нишлибез инде?» – дип әйтеп куя да, аннан барысы да үз эзенә төшә. Ул – авыл малае иде, авыл малае булып калды да.

Рәдифә СИБАГАТУЛЛИНА:
– Ул – гаиләбезнең терәге, таянычы иде, балаларыбыз аның үрнәгендә тәрбияләнде. Рәшит, Рөстәм, Роза тормышта үз урыннан тапты, игезәкләребез мәктәптә белем ала. Әтиләренең, аларның да үсеп җитеп, тәрбияле, белемле булуларын бик күрәсе килгән иде. Әмма тормыш без теләгәнчә генә түгел шул, иншала, игезәкләребез дә сынатмас. Һәйкәл Мәскәүдә Татарстан җитәкчелеге ярдәме белән эшләнде. Авыр чакта гаиләбезгә ярдәм кулын сузган, кадерлебезнең исемен мәңгеләштерүгә зур өлеш керткән Рәисебез Рөстәм Миңнехановка, Рәис Администрациясе җитәкчесе Әсгат Сәфәровка чиксез рәхмәтлебез.

Ил ташламас

Татарстан көчтәнәче

Әбиләр дә булыша, бәбиләр дә. Республикада яшәүчеләр махсус хәрби операциядәге егетләрне онытмый. Һәркем үзеннән өлеш кертергә тырыша. Оекбаш бәйлиләр, мич ясыйлар, токмач кисәләр, хат язалар. Районнарда тагын ниләр эшләнүен белештек. Татарстан халкы илнең яңа төбәкләрендә яшәүчеләргә дә ярдәм итәргә тырыша.

Буадан 8 тапкыр гуманитар ярдәм озатканнар. Бишесен – Ватанны саклаучы егетләргә, икесен – Лисичанск, берсен Рубежное шәһәрендә яшәүчеләргә илтеп тапшырганнар.

– Өлешчә мобилизация башланганнан бирле без кулдан килгәннең барысын да эшләргә тырышабыз. Район халкына һәм иганәчеләргә рәхмәт, – ди район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Лилия Садретдинова. – Махсус хәрби операция зонасына 7 машина җибәрдек. Егетләр нәрсә сорый – шуны илтәбез. Хәзер суыклар башланды. Шуны истә тотып, якташларыбыз егетләр өчен мичләр ясады. Кыскасы, солдатларга кирәк-яракларның барысын да җыеп алып барабыз. Районда берәү дә тик тормый. Егетләр авырмасын, туган якның җылысын тойсын өчен, хатын-кызлар үзебезнең болыннарда үскән үләннәрдән чәйләр ясап җибәрде. Әле дә токмач кисү эшләре, маскировка челтәрләре үрү дәвам итә.

Ә егетләргә иң кадерле бүләк хатлар һәм рәсемнәр икән. Бакчага йөрүче сабыйларның рәсемнәрен алар күкрәк кесәләрендә йөртәләр. Исән-сау әйләнеп кайтуларын теләп язган хатлар да куенда дога белән бергә йөри, ди.

– Районда экология юнәлешендә эшләүче балалар бакчасы бар. Анда сабыйлар әти-әниләре, тәрбиячеләре белән яшелчәләр үстерә. Быел шул сабыйларның нәни кулларының көче кергән уңыш егетләргә китте, – ди Лилия Садретдинова. – Олы яшьтәгеләр аеруча актив. Пенсия акчаларын тотып килүчеләр бар. Әле күптән түгел яшелчәләр җибәрдек. Район халкы бәрәңге, кишер, суган, сарымсак алып килде. Күп итеп бал да бирүчеләр бар. Үзебезнекеләрне ташламыйбыз, без күңел белән алар янында.

Аксубай район мәдәният йорты директоры Алексей Тимирясов җитәкчелегендәге волонтерлар Лисичанск шәһәрендә яшәүчеләр өчен ярдәм җыя.

– Районның туган якны өйрәнү музеенда гуманитар ярдәм җыю пункты оештырдык. Битараф булмаучылар үзләреннән өлеш кертә. Әлегә күпме әйбер җыелганын әйтә алмыйм. Әмма әз түгел, – ди ул. – Без бер тапкыр ярдәм җыеп җибәргән идек инде. Бу юлы мәдәният өлкәсендә һәм белем бирү оешмаларында эшләүчеләр ярдәм итәргә теләк белдерде. ЛНРда яшәүчеләр өчен төзелеш материаллары җыябыз. Шулай ук азык-төлек тә китерәләр. Бу эштә катнашкан һәркемгә рәхмәтлебез. Без – нинди генә хәл булмасын, авырлыкны бергәләп күтәрергә тиеш. Тынычлыгыбыз һәм аяз күгебез өчен без егетләргә рәхмәтле. Алар барысы да безнеке. Исән-сау кайтуларын көтеп калабыз.

Биектауда яшәүчеләр дә зур эштән читтә калмый. Марина Куцакованың ире хәрби, Ватан сагында. Үзе хәзер волонтерлык белән шөгыльләнә.

– Волонтерлар, районның социаль яклау бүлегенә килеп, маскировка челтәрләре үрәләр. Аларның барысына да зур рәхмәт. Волонтерлар гына түгел, пенсионерлар, төрле оешмада эшләүчеләр, мәктәп укучылары да челтәр үрүдә катнаша. Егетләргә махсус киемнәр дә тегеп җибәрүчеләр бар. Кыскасы, ярдәм итүчеләр күп, – ди ул.

Биектауда яшәүче Амалия Успенская беренче көннәрдән үк егетләр өчен җылы киемнәр тегә башлый. Өенә сыймагач, райондагы бер бинага килеп урнаша. Аңа ярдәм итәргә теләүчеләр дә табыла. Бүген Амалиянең тегү цехында 68 кеше хезмәт куя. Көн-төн эштә алар. Китүчеләр кабат килә.

Зәй волонтерлары махсус хәрби операциядә катнашучыларга әзер ашлар ясый башлаган. Аларны тиз генә пешереп була икән. Шулай ук алар егетләргә окоп шәмнәре дә ясый, маскировка челтәре үрә. Бу хакта безгә район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы Марат Хәбибуллин сөйләде. Аның сүзләренчә, ярдәмнән берәү дә читтә калмый. Район халкы Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләрендә яшәүчеләргә дә, егетләребезгә дә булышуын дәвам итә.

– Ватан сагында торган егетләрнең гаиләләрен дә онытмыйбыз. Алар һәрчак безнең янәшә икәнне тоеп яши. Кулдан килгәнчә аларның тормышын җиңеләйтергә тырышабыз, – ди Марат Хәбибуллин. – Гуманитар ярдәм җибәргәндә, якыннарына исемле посылкалар юллаучылар күп. Безнең волонтерлар аларны егетләргә тапшыра. Ни генә җибәрсәк тә – аларда туган як җылысы бардыр дип ышанам мин. Халкыбыз тырыш. Җылы оекбашлар бәйлиләр, тәм-томнар да әзерлиләр.

... Социаль челтәрләрнең берсендә Яңа елда сабыйларның теләкләрен үти торган төркем бар. Шунда бер бала менә болай дип язып куйган: «Кыш бабай! Узган ел мин синнән берни сорамадым. Быел да әллә ниләр алып азапланма! Минем әтиемне бик тә күрәсем килә. Сеңлем дә сагына. Ансыз бик читен бит. Өйгә кайтар әле әтине». Газизләрен көткән һәр кешенең теләкләре кабул булсын иде!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сан

✓ Бер ел эчендә Казаннан Лисичанск һәм Рубежноега **11 партия** гуманитар йөк (**1176,1 тонна** товар) җибәрелгән.

✓ «Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы бүлекчәсеннән махсус хәрби операциягә барлыгы **123 йөк машинасы** җибәрелгән. Бу **1887 тонна** гуманитар ярдәм дигән сүз.

✓ «Зәкят» фонды ел дәвамында махсус хәрби операция зонасына **17 мең**нән артык хәләл тушенка һәм консерва җибәргән. Барлыгы – **7 тонна** гуманитар йөк.

✓ Теләге булганнар ярдям.рф сайтында тулырак мәгълүмат белән таныша ала.

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Түземлек һәм түземсезлек

Сез түзем кешеме? Түземлелекне уңай сыйфат дип саныйсызмы, әллә, киресенчә, тискәрегә кертәсезме? Түземлелекнең чиге, чамасы нинди булырга тиеш? Толерантлык – шул ук түземлелекме? Халыкара түземлелек көне җиткәндә, шушы сорауларга җавап эзләп карыйк әле.

Иң соңгы сорауга җавап әлеге датаның инглизчә яңгырашыннан килеп чыга. Inter-national Day for Tolerance, ягъни түземлелек шул ук толерантлык булып, ике төшенчә арасына һич икеләнми тәңгәллек билгесе куярга мөмкин. БМО гамәлгә керткән бу дата, барыннан да бигрәк, кеше затлары холык-фигыле, белеме, эше, социаль статусы, милләте, төрледән-төрле булып та, теләсә нинди очракта, хәлдә дә, бер-берсенә ихтирамлы, сабыр мөнәсәбәт сакларга тиешлеген ассызыклый. Милләт, халыкларны да бер-беренә карата түзем булырга, бер-берсенең мәнфәгатьләрен санлап яшәргә, телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен хөрмәт итәргә чакыра.

Түземлелек һәркайда кирәк. Коллективта да, гаиләдә дә, хәтта урамда һәм транспортта да. Бик түземсез, чебен тисә дә, чер итә торган затлар булган кебек, ифрат та түземле кешеләр дә бар. Студент чакта без, шаярып, бер-беребезгә шундыйрак сорау-табышмак бирергә ярата идек: гадәттән тыш түземлелек (сверхтерпимость) нindирәк була? Җавап: гадәттән тыш түземлелек ул – авызга бер йотым су кабып, электр плитәсенә утыру һәм шул суның кайнап чыкканын көтү. Әлбәттә, андый түземлелек юмор рәвешендә генә була ала. Тик менә түземлелекнең гадәти, үтәргә мөмкин булганы, тиешлесе дә, ни кызганыч, җәмгыятьтә – кешеләр арасында булсын, дөнья масштабында – халыклар арасында булсын, бик үтәлми, күзәтелми шул әле.

Гаилә корган һәр ике парның берсе өч ел да яшәми аерыла икән, нинди түземлелек, нинди ихтирам, бер-береңнең хәленә керә белү турында сөйләргә мөмкин?! Проблеманың сәбәпләре дә билгеле кебек. Җәмгыятебездә, инде ничә еллар булыр, бала-чага культы. Барысы да алар өчен. Ата-аналар ярыша-ярыша аларны киендерә, сораган берен алып бирә, балигълык яшенә җиткәнче дә, аннан соң да аларның бар теләкләрен сүзсез үтәп килә. Үзләрен кыса-кыса акча түләп укыту дисеңме, машина, фатир алып бирүләр, олы кредитлар ала-ала туй үткәрүләр дисеңме – барысы-барысы да. Ата-ана газизенә бер нәрсәне генә бирергә оныта. Ул да булса тиешле тәрбияне – аның да якын кешеләрне хөрмәт итә, алар мәнфәгатьләрен дә күрә, һәрдаим сабыр-түзем була белү дигән ягын. Әзергә-бәзер яшәгән, көйләтергә, үз көен генә көйләргә өйрәнгән эгоист түзем була алмый. Яшьләр җиңел килгәнгә, өелеп килгәнгә, көч түкми килгәнгә өйрәнеп үсмәсен, сабырлыкка яшьтән үк күнексен иде дә бит. Шунысын да искәртик: һәртөрле түземсезлекнең төбендә тәрбиясезлек кенә түгел, гыйлемсезлек, культурасызлык та ята булыр.

Түземлек-сабырлык дигәндә, тормышта алда язылганның капма каршысына тиң күренеш тә очраштыргалый. Гомер буе салмыш иргә, төрле җәберләүләргә түзеп яшәгән хатыннар, парын санга сукмаган явыз хатын белән тормыш йөген тарткан ирләр, холыксыз җитәкчегә түзгән хезмәткәрләр – болары чагыштырмача өлкәнрәк буын кешеләре арасында күзәтелә. Яшьләр очрагында түземлелек җитмәсә, дефицитта булса, икенче очракта ул гадәттә артыкка киткән, чикне узган булырга да мөмкин. Артыкка киткән түземлелектә шулай ук бер яхшылык та юк. Андый түземлелек – үз-үзеңне хөрмәт итмәү генә түгел, үзеңне эштән чыгару да әле ул.

Милләтара хәлләрдә дә түземлелек профициты, аның чамадан артуы уңай күренеш була алмыйдыр. Без үзебезнең милләтне дә еш кына артыкка киткән толерантлыкта гаеплибез. Һәм бу дөрес тә. Шул ук Кавказ, Урта Азия кешеләре шәһәр урамын яңгыратып, үз телләрендә сөйләшеп, көлешеп барганда, үз республикасында яшәгән татар алай эшләргә кыенсына. Ул сөйләшкәндә дә ипле генә сөйли, рус кешесе килеп кушылса, шунда ук русчага күчә. Мин еш кына үземнән булса да: «Ни өчен шулай?» – дип сорап куям. Җавап эзләп әллә ни ерак китәсе түгел. Кавказны Россиягә кушканга барысы гасыр ярым. Татар, дигәндә, ул инде биш гасырга якын башка халык кулында. Шул сәбәпле телибезме без аны, теләмибезме, кире селекция дигән процесс та шул гомер бара.

Кыюлар, горурлар, гыйсъянчы холыклылар үткән гасырларда ук, Батырша, Карачурин фетнәләре чорыннан башлап, узган гасырның 30 нчы еллар террорына чаклы асылып-киселеп, юкка чыгарылып килгән. Кыюсызлар, түземнәр, куркаклар, баш ия белгәннәр кала торган. Кыюсыздан кыюсыз, түземле, артык толерант яңа буын яралган. Биредә тагын шундый сорау да тумый кала алмый: ник безне үз кулына алганнар безгә толерантлык күрсәтми, ник хәлебезгә керми? Керми, чөнки алар ил бер кавем вәкилләреннән генә торганда бөтенрәк, гайрәтлерәк була, дип фикерли. Икенчедән, «кем көчле – шул хаклы» принцибыннан әле беркемнең дә баш тартканы юк. Дәүләтле дәүләтсездән һәрчак көчлерәк. Без әле ярар, шул ук Кытайда, мәсәлән, тугандаш уйгур халкы даими эзәрлекләнә, хәтта геноцидка дучар ителә. Азчылык халыклар һәрчак аз санлы булганга, түзем булганга, дәүләтсез булганга «гаепле». Фән, технологияләр чәчәк аткан XXI гасырда да вазгыять үзгәрми. Шушы заманда да, Крылов мәсәлендәгечә, Бүре Куянга: «Минем тамагым ач булганга гына гаепле син», – ди…

Толерантлык, дигәндә, махсус көн, дата билгеләү, декларация-теләкләр, әлбәттә, яхшы. Ә менә аларның үтәлмәве бик тә начар. Әлеге җәһәттән БМО дигән оешманың төрле гаделсезлеккә, кемнәрнеңдер түземсезлегенә чик кую рычаглары, көче, вәкаләтләре булсын иде, диясе килә. Табигать, андагы флора, фауна күптөрле булган кебек, кешеләр, халыклар, милләтләр дә теле, мәдәнияте белән дә, холкы, уйлары буенча да төрле. Күптөрлелек ул – байлык. Фикер, инанулар төрлелеге дә – байлык. Бер-беребезгә түзем булсак, сакласак иде без ул байлыкны.

ОЗЫН ГОМЕРЛЕ ӘЛИФБА

Вәгыйзов укулары

Тышлыгына букча тоткан ак алъяпкычлы кыз төшерелгән, янәшәсендә бәләкәй генә маэмай йөгереп бара… Исегезгә төштеме? Әлбәттә, күңелләргә онытылмаслык булып сеңеп калган әлифба китабы турында сүз бара. Шушы көннәрдә Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятендә дәреслекнең авторлары Сәләй (Сөләйман) Вәгыйзов белән аның хәләл җефете Рәмзия Вәлитова истәлегенә багышлап, беренче тапкыр Вәгыйзов укулары үткәрелде.

Әлифба авторлары Сәләй Вәгыйзов белән Рәмзия апа Вәлитованың укытучылар һәм тәрбиячеләр өчен 40ка якын хезмәте бар. «Кызыклы грамматика», «Язу һәм матур язу» дәфтәре, төрле методик кулланмалардан бүген дә файдаланалар. Әлифбалар да берничә: 6 яшьлекләр өчен, өч сыйныфлы башлангыч мәктәп өчен, «Рәсемле әлифба», хәтта латин графикасы белән дә дәреслек төзергә өлгерәләр.

Изге китап

– Безнең якта мәгърифәтле халык яши, – дип басым ясады район башлыгы Илшат Нуриев, – 300гә якын язучыбыз һәм шагыйребез бар. Габдулла Тукай, Мөхәммәт Мәһдиев, Гомәр Бәширов кебек якташларыбыз белән бик горурланабыз. Әмма әлифба үзенә аерым бер урынны биләп тора. Уйлап карасаң, башка сыймаслык хәл кебек бит. Сәләй ага белән Рәмзия апа төзегән китап халыкка 57 ел буена хезмәт итә, шушы вакыт эчендә өч тапкыр үзгәреш кичерә, бер миллионнан артык тираж белән чыгарыла.

Бу фикерне Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов дәвам итте.

– Дөрес, миңа Вәгыйзовлар әлифбасын укырга туры килмәде, – диде ул, истәлекләргә бирелеп. – Һәр чорның үз әлифбасы була. Ул безнең өйдә һәрвакыт изге китап булып саналды. Әнием укытучы булып эшләгәнлектән, күрәсең, мин инде мәктәпкә аяк басканчы ук китапның һәр битен ятлап бетергән идем. Ярты гасырдан артык белем бирергә яраклы дәреслек ни дәрәҗәдә камил булырга тиеш? Моны хәтта күз алдына китерүе дә авыр. Гомумән, әлифба иҗат итәр өчен беренче чиратта туган телнең камил һәм зәвыклы булуы шарт. Ә без әлифбасыз яшәмәдек. Димәк, татар теле иң матур сыйфатларга ия дигән сүз бу.

Татарстан мәгариф министры Илсур Һадиуллин да соклануын яшермәде.

– Безне кеше иткән, тормыш юлына басарга ярдәм иткән әлифба авторларын онытырга хакыбыз юк, – диде ул. Хатирәләргә дә бирелеп китте. – Мине дә башлангыч сыйныфларда әнием укытты. Мәктәпкә укырга-язарга өйрәнеп бардым. Дәрес вакытында бик белеп бетермәгәннәргә пышылдап әйтеп утырган өчен, өйгә кайткач, партада тик кенә утыр, дип эләккән чаклар да күп булды.

Язмышлар

Үземне искиткеч бәхетле кеше итеп сиздем бу кичәдә. Кайчандыр Сәләй ага һәм Рәмзия апа белән сирәк кенә булса да аралашып, күрешеп яшәдем чөнки. Мин укыган чорда алар инде укытучылык эшен ташлаган, әмма училищега һәр көнне диярлек килеп йөриләр, фән белән шөгыльләнәләр иде.

Әлифба авторларын мәңгеләштерү эшен беренче булып педучилищеда күп еллар директор булып эшләгән, исеме легендага әверелгән Илдус абый Сәгъдиев башлап җибәрде дип уйлыйм. Бервакыт ул болай дип шалтыраткан иде: «Сеңлем, бик эчем пошып йөри әле. Безнең Сәләй ага белән Рәмзия апа архив тузаннарында югалып калыр кебек. Искә алучы да юк бит. Дөрес, педучилищеда Әлифба музее төзедек. Әмма алар хакында илнең түгел, дөньяның һәр почмагында яшәүче милләттәшләребез белеп торырга тиеш. Мактаулы исемнәр бирелмәсә дә, халык академиклары бит алар. Кайт әле. «Ватаным Татарстан»да язып чыгыйк әле», – диде. Шуннан тукталып калмады Илдус абый. Башкаларны да үз артыннан ияртә алды. Конференцияләр үткәрелде, Әлифба һәйкәле төзелде, Сәләй аганың туган җирендә, Самара өлкәсендәге Камышлы районының Татар Байтуганы авылында тагын бер Әлифба музее пәйда булды. Һәм менә киләчәктә өч елга бер тапкыр үткәрергә тәгаенләнгән Вәгыйзов укулары шаулап-гөрләп узды. Хәзер инде бу эшләрне остазыбыздан кабул итеп, педагогия көллиятенең бүгенге директоры Гөлнара Гарипова дәвам итә.

Арчада Сәләй ага белән Рәмзия апаның язмышын Тукайныкы белән чагыштырырга яраталар. Икесе дә ятимлекнең ачысын-төчесен татыган кеше алар. Алты айлык чагында Сәләй аганың әтисе вафат була. Туган ягына юл тоткан әнисенә баланы бирмиләр. Янәсе, малай кеше әтисе нигезендә тәрбияләнергә тиеш. Әмма әбисенең хәле авыраеп китә һәм ул Сәләйне авылдашлары Гататдин абый белән Гайшә апага асрамага бирергә мәҗбүр була. Рәмзия апа исә – Башкортстаннан. Эстәрлетамак балалар йортында тәрбияләнә. Егет белән кызны Казан педагогия институты кавыштыра. Арча педагогия училищесына кайтып эшли башлагач та, бәхетле тормышка сугыш чик куя. Завуч булып эшләгән Сәләй ага фронтка киткәч, аны Рәмзиясе алыштыра. Көн дә хәбәр көтеп, исән кайтуына өмет белән яши ул. Әмма өмете тиз генә акланмый. Сәләй ага Харьков янында әсирлеккә төшә. Аннан котылгач, аны Печора лагерена сөрәләр. Рәмзия апа, ике нарасыен җитәкләп, ике мәртәбә ире янына бара. Мондый сәяхәтләр бик аянычлы тәмамлана: аны эшеннән куалар. Ә ире, сабыйларны саклап калу ниятеннән, аңа үзеннән баш тартырга киңәш итә. Кайткач та, бары тик кайчандыр үзләре укыткан, ул вакытта зур урыннарда эшләгән укучылары ярдәмендә генә кабат педучилищега эшкә урнаша алалар.

Кандидат булмаган башы белән…

Көчле рухлы була Сәләй ага белән Рәмзия апа. Авырлыклар, гаделсезлекләр бу икәүнең бер булып типкән йөрәкләрен ташка әйләндерә алмаган, күңелләре тупасланмаган аларның. Шулай булмаса, җиң сызганып, нәкъ менә сабыйлар өчен булган дәреслеккә – әлифбага тотына алырлар идеме икән алар?!

1960 елда төзелә башлаган дәреслек балалар кулына 1965 елда гына барып ирешә. Татарстан Мәгариф министрлыгы уздырган конкурста бу дәреслек икенче урынны ала. Беренче урын бирелми. Ә башта… Сәләй аганы министрлык бинасыннан: «Фән кандидаты да булмаган башың белән бу тирәдә буталып йөрмә», – дип, әлифбасы-ние белән борып чыгаралар. Ярый әле түрәләр арасында аңлый белгәннәре, Сәләй ага әлифбасына озын гомер юраучылары да табыла. Ни өчен шулай? Бу сорауга бүген Илдус Габдрахманович болай дип җавап бирде:

– Беренчедән, Сәләй ага белән Рәмзия апа икесе бер йодрык булып, тирәнтен аңлап эшләделәр. Кирәк вакытта бер-берсен тәнкыйтьләп алырга да күп сорамый иде алар. Гомумән, аларның яшәү рәвеше башкалар өчен бер мәктәп булды. Икенчедән, китап беренче тапкыр нәшер ителгәч, тукталып калмадылар. Төрле өлкәдәге үзгәрешләрдән чыгып, китапка төзәтмәләр кертә бардылар. Өченчедән, бу дәреслекне эшләргә тотынганчы, егермедән артык төрле халыкның әлифбаларын ныклап өйрәнделәр. Һәрберсенең яхшы якларын үзләренә алдылар.

Вәгыйзов укуларында без тагын да сөенечле хәбәрләр ишеттек. Тормыш таләп иткән тиешле төзәтмәләрдән соң, Илсур Һадиуллин бу әлифбаны федераль исемлеккә кертү мәсьәләсен хәл итәргә сүз бирде. Марат Әхмәтов исә Әлифба һәйкәлен яңартуны йөкләмә итеп алды.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ ПРЕЗИДЕНТЫ РИФКАТЬ МИҢНЕХАНОВ:

«АРХЕОЛОГИЯ АРАЛАРНЫ ЯКЫНАЙТА»

Фән өлкәсендәге ачышлар, тарих төпкелендә актарынулар, чыннан да, шулай дип әйтергә мөмкинлек бирә. Татарстан Фәннәр академиясендә Идел буенда яшәгән борынгы мадьярларның тарихы турында өч монография тәкъдим ителде. Бу – Россия һәм Венгрия галимнәренең уртак җимеше.

Элемтәләр ныгый

Кичәдә Россия галимнәре генә түгел, Венгрия, Казахстан, Кытай һәм Иран вәкилләре дә катнашты. Венгрия Католик университетының онлайн элемтәгә чыккан профессоры Атилла Түрк (ул Татарстанда шактый гына казу эшләрендә катнашкан) бу җәһәттән: «Венгрларның татар җирендәге тарихы – безнең илләрне бәйли торган тема», – диде. Рифкать Нургалиевич та нәкъ менә фән өлкәсе аша барлыкка килгән дәүләтара элемтәләрнең мөһимлегенә басым ясады. «2019 елда Алексеевск районындагы Олы Тигәнәле авылы янындагы зур казу эшләрендә 60 кеше катнашты. Шуларның 8е Венгриядән килгән иде», – диде ул. Венгриянең Казандагы илчесе Сергей Сюч та үз фикерләрен җиткерде: «Бүгенге шартларда халыкара элемтәләрне ныгыту өчен әллә ни мөмкинлекләр юк. Шуңа күрә күбрәк мәдәният һәм фән өлкәсенә өмет багласак кына инде. Әйтергә кирәк, алар арасында археология төп рольне уйный». Бу фикер Казахстанның Казандагы илчесе Ерлан Искаков күңеленә дә хуш килде. «Без дә венгрлар салган эздән барырга әзербез», – диде ул.

Олы Тигәнәле серләре

Бу хәл 1974 елда була. Алексеевск районының Олы Тигәнәле авылы янында юл салганда гадәти булмаган каберлеккә юлыгалар. Ни икәнен ачыклау өчен, шунда ук Казаннан археологларны чакырталар. Тик тикшеренүчеләр аптырашта кала, чөнки бу көнгә кадәр мондый каберлекләрне бөтенләй очратканнары булмый. Казу эшләренә археолог Елена Халикова килгәч, шундук бу каберлектә мадьярлар күмелгәнен әйтә. Беренче нәтиҗәләрне Венгрия галимнәренә җиткергәч, алар өчен бу чын мәгънәсендә сенсациягә әверелә. Тикшеренү нәтиҗәләре беренче тапкыр 1981 елда Венгриядә немец телендә басыла. Бу яңалык 30 елга якын рус чыганакларында бөтенләй телгә алынмый. Күптән түгел генә археолог Альфред Халиковның язу машинасында басылган хезмәтләре табыла. Шуның нигезендә «Великая Венгрия между Волгой и Уралом» дип аталган хезмәт нәшер ителә. Бу эшне башкарып чыгу өчен остазның шәкертләре ярдәмгә килә.

Урал тауларыннан – Дунай ярларына

Идел буенда мадьярларның яшәве турында археологик белешмәләр генә түгел, тарихи чыганаклар да бар. Чарада шундый бер вакыйганы искә төшерделәр. 1235 елда бүген Татарстан урнашкан территориягә Венгриядән католик монах Юлиан килеп чыга. Ул бабаларының туган җирен эзләп килә. Сәяхәт иткәндә Идел буе Болгарстанына килеп чыга һәм Биләрдән ерак түгел мадьяр хатын-кызын очрата. Ул аңа милләттәшләре яшәгән урынга кадәр ике көнлек юл икәнлеген әйтә. Галимнәр бу хатын-кыз бүгенге Чистай районы биләмәсе турында әйткәндер дип фаразлыйлар. Шулай да сорау туа. Мадьярлар Идел буена, аннан Венгриягә кайдан һәм ничек килеп чыкканнар? Венгриядә төшерелгән һәм махсус безнең өчен рус теленә тәрҗемә ителгән фильмны карагач, бу сорауга да җавап табылды. IX–X гасырлар чигендә мадьярларның борынгы бабалары Көньяк Уралдан Көнбатышка таба юл ала. Алар күчмә халык була. Хәрби осталыклары искиткеч югары дәрәҗәдә булганлыктан, далаларда яшәүче көндәшләренә бирешмичә, төпләнеп калган биләмәләренә кадәр килеп җитәләр. Әмма тукталып калмыйлар әле. X гасыр башында бүген Франция, Италия, Германия, хәтта Испания урнашкан территорияләр буйлап, басымчаклык итеп йөриләр. Европа дәүләтләренә көтелмәгән һөҗүм итүләр бары тик XI гасырда монархиягә нигез салынгач кына туктатыла. Аңлашыла ки, күчмә халыкларның төрле җирләрдә озак вакытлар төпләнеп яшәгән урыннары да була. Олы Тигәнәле авылы янындагы каберлек шуңа дәлил булып тора.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Фәннәр академиясендә үткәрелгән чарада «Великая Венгрия между Волгой и Уралом», «Армиевский курганно-грунтовой могильник» һәм «Поясные наборы населения Ветлужско-Вятского междуречья IX–XI вв.» китаплары тәкъдим ителде».

ЛАНДЫШ ГАРӘФИЕВА:

«ТӨРКИЯДӘН ТУГАН ЯККА КИЛЕН БУЛЫП КАЙТТЫМ»

Арабыздан беребез

Балтачта яшәүче Ландыш Гарәфиева – чит телләр белгече. Биш ел – Казанда, дүрт ел Төркиядә белем алган. Башкалада да, солтан илендә дә калу мөмкинлеге була торып, туган ягына кайтып төпләнгән ул. Районда телләр өйрәтү үзәген булдырып, балаларга чит телләр өйрәтә хәзер.

– Тумышым белән Балтачтан мин. 6 нчы сыйныфны тәмамлагач, Казанга күчендем. Күченүемнең төп сәбәбе татар-төрек лицеенда белем алуым иде, – дип искә ала Ландыш. – 5 ел Казанда яшәп, андагы көнкүрешкә дә ияләштем, бу шәһәрне үз итеп яшәдем. 11 сыйныфны бетергәч, Төркиягә укырга кердем, шулай итеп беренче югары белемемне Төркиядә алдым.

Белем эстәү урыны итеп Төркияне сайлавын әйткәч, Ландышка әтисе шарт куя.

– «Кызым, көчең җитсә, без каршы килмибез. Ләкин укып бетергәч, туган якка кайтасың, анда калмыйсың», – диде әти. Теләк тә түгел, боерык булгандыр бу (*көлә*). Әтидән дә мондый сүз ишеткәч, Төркиядә төпләнеп калу максаты куелмады, билгеле. Хәер, мин инде киткәндә үк кире кайтырмын дигән теләк белән киттем, – ди Ландыш. – Югалткач кына кадерен аңлыйсың, диләр бит әле. Мин бернәрсә дә югалтмадым, әмма туган яктан, якыннарымнан аерылып тордым. Бу аерылу Татарстанның, якын кешеләрнең, үз ризыкларыбызның кадерен белергә өйрәтте. Сагынган чаклар да булмаган түгелдер. Студент елларым тоташ бәхеттән генә торды, дип әйтә алмыйм. Бөтенләй башка белем бирү системасы, башка мохит бит. Ләкин, бернигә дә карамастан, бирешмәдем. Бу юлны сайлагач, максатыма ирешеп, укып бетереп кайтырга тиеш идем инде мин. Хәзер инде студент чакларымны сагынам (*көлә*).

Ландыш хәзер – әни һәм кадерле хатын. Тормыш иптәше дә – Балтачныкы.

– 4 курсны тәмамлаганда, булачак тормыш иптәшем кияүгә чыгарга тәкъдим ясады. Шулай итеп, тугыз елдан соң, Төркиядән Балтачка килен булып кайтып төштем, – ди әңгәмәдәшебез.

Дөнья күреп, чит илдә белем алып кайткан кызга аптырраучылар да булмый түгел. «Кем инде Төркиядән авылга кайтсын?! Монда нишләрсең, нинди эш табарсың?!», «Шулкадәр телләр белеп, әрәм булып ятасың» ише сүзләрне бик күп ишеткән Ландыш.

> Мин гаилә корам дип, иремә ышанып, бу юлны сайладым. Әлбәттә, шәһәрдә мөмкинлекләр күбрәк. Ләкин, карьера төзим дип, калада калу урынына, авылга кайтып, үз ояңны кору өстенрәк иде минем өчен. Бүгенге тормышыма карап, шөкер, дим. Мине кадерләп торган ирем, балаларыбыз бар. Без матур гаилә булып яшәргә омтылабыз.

«Балтачка кире кайтасың булгач, анда кадәр барып укырга кирәк идеме?» – диючеләр әле дә бар. Мин андый сорауларга елмаеп кына җавап бирәм.

Төркиядән кайткач, Балтачта инглиз телен укытырмын дигән теләге була Ландышның. Мәктәпнең, билгеле, андый белгечкә ихтыяҗы бар.

– Төркиядә мәгариф системасы башка. Анда, укып бетергәч, имтиханнарны уңышлы бирде, фәлән факультетны тәмамлады дигән белешмә бирәләр. Шушы белешмә белән Төркиядә эшли башларга мөмкин. Мин алган дипломымны Мәскәүдә раслатырга тиеш идем әле, дипломның төп нөсхәсе дә кирәк. Ә бит 1 сентябрьдә инде укытучы эшкә урнашкан булырга тиеш, – ди Ландыш. – Миңа «продленка»да тәрбияче булырга тәкъдим иттеләр. Дипломны кулга алгач, укытучы булырсың, диделәр. Әлбәттә, миңа моны кабул итү авыр булды. Тырышып телләр өйрәнүем бушка булган кебек тоелды... Ярый әнием тынычландырды. «Тиз генә берәүне дә директор итеп куймаслар. Барысы да – үз кулыңда. Сабыр бул!» – диде. Кыскасы, бу эшкә баш-аягым белән чумдым, балаларга ияләштем.

Көттереп кенә дипломы кайта Ландышның. Укытучы вазыйфасына юллар ачыла, димәк. Әмма Ландыш әни булырга әзерләнә инде бу вакытта.

– Декрет ялына бүлендем. Һәм нәкъ шул мәлдә хыялымны чынга ашыра башладым: чит телләр мәктәбен булдыру һәм укыту! Декрет ялында буш вакыт күп бит. Ничек укытырга мөмкин, нинди программа кулланырга – барысын да уйладым. Ирем белән киңәшләштем, ул мине хуплады, – дип сөйләде Ландыш. – Әлбәттә, эшләребез җиңел генә бармады. Үзәкне ачып, ике ай эшләгәч, коронавирус башланды. Мәктәпләр эшен туктатты. Бу вакытта аудиториямнең яртысын диярлек югалттым. Әмма бирешмәдем. Мин бу эшкә, дөресен әйтим, бизнес буларак та карамадым. Шөкер, беренче көннән үк укучыларым күп булды.

Ландышның мәктәбендә төрек, инглиз телләрен өйрәнергә мөмкин. Балаларга да, зурларга да дәресләр каралган.

– Замана белән бергә атларга тырышам. Балаларга укытыла торган дәресләр актуаль булырга тиеш, – ди Ландыш. – Инглиз теленә кызыксыну барда, әле минем мәктәпкә дә ихтыяҗ булыр. Хәзерге көндә ата-аналар да өстәмә белем бирүгә җаваплы карый. Бу бик яхшы. Без үскәндә җыр, бию түгәрәге генә иде. Баланы белем алуга этәрү – күркәм күренеш.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

РӨСТӘМ ӘХМӘТ УЛЫ КИЛДЕБӘКОВ

(30.03.1934 – 09.11.2023)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. Россиянең танылган рәссамы, монументалист, график Килдебәков Рөстәм Әхмәт улы 9 ноябрь көнне 90 нчы яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Рөстәм Килдебәков 1934 елның 30 мартында Казан шәһәрендә туган. 1954 елда Казан сәнгать училищесын, 1960 елда Львов гамәли һәм декоратив сәнгать институтын тәмамлаган. 1961–1998 елларда Татарстан сәнгать фонды бүлегендә эшләгән. 1987 елда СССР Рәссамнар берлегенә кабул ителеп, Татарстан Рәссамнар берлеге идарәсе әгъзасы булып торган.

Рөстәм Әхмәт улы монументаль-декоратив сәнгатьтә, станоклы рәсем сәнгате, графика, гобелен сәнгатендә күпкырлы талантын күрсәтте. Татарстан башкаласының әһәмиятле, тарихи йөзенең бер өлеше булып торучы бизәкләре – «Волга» кунакханәсе бинасы фасадында «Казань – порт пяти морей», тимер юл вокзалы бинасы фасадында – «Казань – столица Татарии», Казан илкүләм тикшеренү-технологик университеты корпусы фасадында «Химия» сграффитолары нәкъ менә аның катнашында эшләнгән.

Рөстәм Килдебәковның станоклы рәсем сәнгате һәм графикасы декоратив яктан бай булуы, образларны бик тирән гомумиләштерүе, төсләр һәм төсмерләрнең төрлелеге белән аерылып тора. «Разговор» («Старик с рыбкой»), «Кружевницы», «Автопортрет на синем фоне», «Портрет жены художника», «Мальчик на красном коне» кебек хезмәтләре, үзенчәлекле талантын ачып, киләчәктәге иҗади үсешен билгеләде.

Ул 1970 нче елларда татар халкы кәсепчелегенә багышланган әсәрләр: «Арские мастерицы», «Арский натюрморт», «Кукморские валенки» һәм башка шундый әсәрләрен иҗат итте. 1980 нче елларда дини традицияләрне («Из лирики Г.Тукая», «Три поэтессы»), шулай ук татар халкы тарихындагы фаҗигале вакыйгаларны («Переселенцы», «Крещение», «Изгои» һәм башкалар) игътибар үзәгенә алды. 1990 нчы елларда исә Коръән образы аша («Старуха с хворостом», «В гости», «Паломники», «Зима в Касимове. Сююмбике с сыном») урта гасыр татар тарихын ачучы әсәрләр сериясен булдырды.

Рөстәм Килдебәковның күпкырлы иҗади эшчәнлеге дәрәҗәле бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – «Фидакарь хезмәт өчен», «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медальләре, Татарстан Республикасы Мактау грамотасы, Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты, «ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе», «Татарстан Республикасының халык рәссамы», «Россия Федерациясенең атказанган рәссамы» дигән мактаулы исемнәр.

Рөстәм Әхмәт улы 2011 елда автордашы, тугрылыклы хатыны Мария Семеновна Килдебәкова белән Габдулла Тукай иҗаты нигезендәге монументаль сәнгать әсәрләре һәм татар халык әкиятләре буенча кулдан сугып эшләнгән гобеленнар сериясе («Су анасы», «Сак-Сок», «Шүрәле» триптихы) өчен Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясенә лаек булды.

Рөстәм Килдебәков гомеренең соңгы көннәренә кадәр үз эшенә, мәдәният һәм сәнгатькә тугрылыклы булды. Иҗат еллары дәвамында күренекле осталарның тулы бер буынын тәрбияләде. Ул иҗади фикер йөртүе, яңалыкка омтылуы, эчкерсезлеге, кешелеклелеге, игелеклелеге, коллегаларын һәм шәкертләрен чын йөрәктән кайгыртуы белән аерылып торды.

Талантлы рәссамның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ, Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН, Ә.Ә. СӘФӘРОВ, И.Х. ӘЮПОВА, И.Р. МЕТШИН, А.В. КРЫЛОВ, А.Л. ВЯТКИНА, Р.М. НУРГАЛИЕВА

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, әнисе

ГАЛИЕВА Розалия Әнвәр кызының

кинәт вафат булуы сәбәпле, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Галиев Марат Ибраһим улының авыр кайгысын уртаклаша.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе рәисе **Гобәйдуллин** Әгъзам Самат улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **Почет ордены** белән бүләкләнде.

***

Физик культура һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүе, күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Зенит» волейбол клубы» автоном коммерциясез оешмасы (Казан ш.) президенты **Кантюков** Рәфкать Абделхәй улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Казан шәһәр Думасы аппаратының баш эксперты – мэр ярдәмчесе **Сәлахов** Марат Фарук улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Россия Федерациясендә самбоны үстерү һәм популярлаштырудагы казанышлары, күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Бөтенроссия самбо федерациясе» Гомумроссия физкультура-спорт иҗтимагый оешмасы башкарма комитеты әгъзасы, «Батыр» олимпия резервы республика спорт мәктәбе» дәүләт автоном өстәмә белем бирү учреждениесе директорының спорт эше буенча урынбасары **Вәлиуллов** Альберт Дамир улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Республиканың социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы директоры **Әйделдинов** Айнур Тәүфикъ улы, мәгариф өлкәсендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, туган телне саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүләре өчен Чувашстан Республикасы Комсомол муниципаль округының «Тукай урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Зарипов** Наил Сабирҗан улы, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе мәгълүмат-методика бүлегенең милли мәгариф буенча методисты **Зиннәтуллин** Раиф Кәримулла улы, «15 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе директоры (Төмән өлкәсенең Тобольск шәһәре) **Хисмәтуллин** Сәет Заир улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесенең әдәби-драма часте җитәкчесе **Муллагалиева** Айгөл Габдулла кызына, рәссам, «Санкт-Петербург Рәссамнар берлеге» төбәк иҗат иҗтимагый оешмасы әгъзасы, «Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге» төбәк иҗат иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Мостафина** Эльмира Әмир кызына **«Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасының «Буа дәүләт драма театры» дәүләт автоном мәдәният учреждениесе драма артисты **Гыйззәтуллина** Гөлназ Вазыйх кызына, «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Закиров** Зөлфәт Хәйдәр улына **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Хезмәт ветераны, «Мирас» ветераннарның үзешчән татар халык хоры җитәкчесе (Казан шәһәре) **Бариев** Наил Мәсгут улына, «Әкият» татар дәүләт курчак театры дәүләт бюджет учреждениесенең ут куючы рәссамы **Гыйбадуллина** Светлана Тәлгать кызына, «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе башлыгы **Нуриев** Рамил Барый улына, «Казан театр училищесы» (техникумы) дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең вокал укытучысы **Фәссахова** Зөлфирә Әхәт кызына, «3 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры (Чаллы шәһәре) **Шумилова** Наталья Анатольевнага **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Киртәле урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган тел (мокша) һәм әдәбият укытучысы **Абраконова** Галина Васильевнага, Казан шәһәре Совет районының «Дербышки поселогы балалар иҗаты үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең педагог-оештыручысы **Антонова** Ләйсән Мансур кызына, Казан шәһәре Совет районының «141 номерлы гимназия» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең химия һәм биология укытучысы **Гәрәева** Эльмира Рафис кызына, Казан шәһәре Яңа Савин районының «Инглиз теле тирәнтен өйрәнелә торган 9 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Камалиева** Татьяна Ивановнага, Казан шәһәре Совет районының «8 номерлы гимназия – Мәгариф үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең физик культура укытучысы **Суслова** Елена Александровнага, Казан шәһәре Совет районының «Катнаш төрдәге 135 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе педагогы-психологы **Шәмсиева** Рәисә Касыйм кызына, Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 54 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Әскәрова** Рәисә Рәис кызына, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Баландыш төп гомуми белем бирү мәктәбе – муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Зәйнуллина** Рушания Хәким кызына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Бакый Зыятдинов исемендәге Карадуган гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Зарипова** Гөлсинә Фаил кызына, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «32 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Мәсәллимова** Мәүлия Минвәли кызына, Чувашстан Республикасы Батыр муниципаль округының «1 номерлы Шыгырдан урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Мтиева** Зәкия Шәйхулла кызына, «Советлар Союзы Герое Г.Г. Рамаев исемендәге милли (татар) гимназия» муниципаль гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы (Саратов шәһәре) **Насыйрова** Идалия Сәгыйть кызына, Казан шәһәре Яңа Савин районының «170 номерлы күппрофильле лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган тел һәм әдәбият укытучысы **Фәйзуллина** Равия Әгъзам кызына **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Алла бирсә

И барыбыз да – Алла бәндәләре инде… Олыгая төшкәч, балаларның кечкенә чагы сагындыра башлый икән. Зур үскән килеш тә бик начар түгел инде алар, тик сабый чакларын барыбер сагынасың, чөнки олы бала ерагая төшә. Аны инде куеныңа алып иркәләп тә булмый, күтәреп тә йөртә алмыйсың, тәм-том белән генә алдый да алмыйсың. Кайчагында иркәлисе килә, куеныңа алып сөясе. Тик алар инде малайлыктан чыгу белән якын китерми башлыйлар, башларыннан сыйпасаң да, сәерсенеп, читкә тайпылалар. Шуңадыр, бәләкәй чакларын сагынасың да кулланышсыз калган ятим назыңны юата-юата оныкларың булуын көтәсең…

Кечкенә улым белән урамдагы киоск яныннан узып барабыз. Бөтен затлы нәрсәләрен зур пыяла тәрәзә алдына тезеп куйганнар, хәтта өлкәннәрнең дә күзе кызыгырлык. Малай, йөгереп барып, шунда каплана. Бала-чага әйберләрен нәкъ аларның буе җитәрлек итеп тезгәннәр. Бу әле берсен, әле икенчесен карый. Сайлый инде үзенә ни кирәген. Бераздан миңа эндәшә:

– Әти, менә бу ничек атала?

– Киндер-сюрприз, – дип аңлатам мин, аның шуны да белмәвенә бераз шикләнеп, – алган бар бит инде аны.

– Монысын алган юк бит.

Мин елмаерга да өлгермим, ул тагын сорый:

– Әти, синең акчаң ничәү?

– Белмим

– Күпме соң?

– Күп.

– Шул киндер-сюрприз ничә сум тора ул?

Мин бәясен әйтәм. Малай баш кага да миңа төбәлә:

– Әти, берәр кайчан миңа шуны алырсың әле. Юк, бүген түгел. Берәр кайчан гына. Акчаң күп булганда гына. Нык-нык күп булганда гына…

Мин алып бирәм инде. Шулкадәр ихлас итеп, оста итеп сораган баланы буш калдырып буламыни?! Мөмкинлегең булганда, шатлана-шатлана аласың…

Алмаган вакытлар да була. Я ул бик кыйммәтле нәрсә сорый, я үзенә зарарлы әйбер, я әлегә ярамый торганны. Бала-чага нәрсәгә күзе төшә, шуны сорый бит инде ул. Аучылар кибетенә керсәң – мылтык, балыкчыларныкында – көймә, спорт товарлары сатыла торган җирдә – груша, гер, бокс бияләе… Кызыксынучан ул, барысын да тотып карыйсы, уйнап-танышасы килә. Тик син ничек кенә яратсаң да, аның өчен җаныңны кызганмасаң да, сораган һәр нәрсәсен алып бирмисең.

Кирәк дип тапканнарын сорамаса да аласың. Авырып китсә, дару кирәк. Кием кирәк, ризык… Китап-дәфтәр… Тик, гадәттә, бала боларның берсен дә сорамый бит, ул тәм-том, уенчык ише нәрсәләргә кызыга.

И барыбыз да – Алла бәндәләре инде… Үзебез дә, ничә генә яшькә җитсәк тә, шул сабый бала хәленнән артык ерак китә алмыйбыз бугай. Туктаусыз нәрсәдер сорыйбыз: «И Ходаем, тегене бирсәң иде, моны бирсәң иде». «Алла бабай», – дип әйтәбез дә аны үзебезнең картәти кебек күреп ялварабыз. Бирмәсә, үпкәлибез… «Юктырсың ла…» – диючеләр дә табыла. Булса да ул гадел түгелдер, безне бар дип тә белмидер, фәкать, әрсез һәм оятсыз кешеләргә генә барысын да мулдан өләшәдер кебек тоела.

Уйлап карасаң, ул безгә иң кирәк нәрсәләрне биргән бит инде. Гомер биргән. Ашар ризык, кияр кием биргән. Сокланып туя алмаслык матурлыклар тудырган, могҗизалар хасил иткән. Гүзәллекне күрер өчен күзләр биргән… Ишеткән-күргәнне кабул итәрлек күңел биргән. Аң биргән, акыл биргән. Иң кирәкле нәрсәләрнең барысын да биргән, аларны санап бетерерлек тә түгел хәтта.

Тик без һаман сорыйбыз… Ә ныклабрак уйлап карасаң, бик авыр хәлгә генә калмасак, иң кирәклеләрен сорамыйбыз бит. Без аннан, гадәттә, уенчыклар һәм тәм-том сорыйбыз… Зур сарайлар, затлы машиналар, чиксез ләззәт, тагын әллә ниләр…

Мин әле Октябрь революциясеннән соңгы еллар белән кызыксынам. Ул чорның түрәләре халыкны рәхәт тормышка чыгарабыз дип тырышканнар бит инде. Ләкин максатларына тулысынча ирешә алмаганнар, халык шул килеш, хәтта элеккедән дә хәтәррәк хәлдә калган. Рәхәт тормышка түрәләр үзләрен һәм якыннарын гына чыгара алганнар. Затлы киенеп, яхшы ашап, кәеф-сафа корып, чамасыз властька ия булып яшәгән шул түрәләргә дә көнләшеп караучылар күп булгандыр. Тик утызынчы еллар ахырына ул түрәләрнең барысы да диярлек кырылып беткән. Туксанынчы елларда да шундыйрак хәлләр булды… Хәрам юл белән килгән мал ул бала кулындагы граната яки мылтык шикелле. Аңа кызыгырга ярамый.

Әгәр кечкенә улыма әтисе мылтык алып бирми икән, бала аны урлап та, башка юллар белән дә алырга мөмкин. Тик моның ахыры гына начар булачак. Нәкъ шуның шикелле үк, әгәр Ходай сиңа сораганыңны бирми икән, аны урлап та, талап та, башкача да алырга була. Тик бу беркемгә дә, беркайчан да бәхет китермәячәк. Чөнки һәр нәрсә кешегә Ходай биргән микъдарда гына кирәк. Артыгы артык. Кеше организмына тимер дә кирәк, тик ул аз-азлап кергәндә, әйтик, алма булып кергәндә генә әйбәт. Пуля яки пычак булып керсә, чүт кенә артыграк була.

Тик без ул хакта уйламыйбыз. Һаман сорыйбыз, нәрсәдер көтәбез, өмет итәбез… Зарланабыз… Бу безгә яшәү рәвешедер, булмаганны булдырудыр кебек тоела. Тормыш үзе шуңа корылган сыман күренә… Ә чынында, булмаганы булдыру – иллюзия генә. Булганын, Ходай биргәнен кабул итеп бетерү өчен генә дә бер гомер җитми бугай әле.

ХАКИМЛЕК КЕШЕНЕ БОЗАМЫ?

Премьера

Иҗат һәм хакимият. Хан һәм шагыйрь. Камал театры яңа премьерасында әнә шул беренче карашка бернинди уртаклыгы да булмаган, әмма һәр чор өчен актуаль булган мәңгелек темага мөрәҗәгать итте.

kamalteatr.ru

Драматург Ркаил Зәйдулланың «Хан һәм шагыйрь» пьесасы буенча «Игезәк» спектаклен режиссер Рамил Гарәев куйды.

«Хан һәм шагыйрь» – Ркаил Зәйдулланың егерме елдан артык элек Алтын Урда чоры риваятьләренә нигезләнеп язылган әсәре. Бирдебәк хан – Чыңгыз хан нәселен дәвам иткән Үзбәк хан оныгы, Җанибәк хан улы. Ул тарихта үз туганнарын – Бату нәселен үтерткән явыз хан буларак калган. Ркаил Зәйдулла исә үз әсәрендә туганнарын Бирдебәк хан түгел, аның урынына тәхеткә менгән дәрвиш шагыйрь кырып бетергән дип фаразлап язган. Нәтиҗәдә шундый әсәр туган һәм озак еллардан соң Камал театры сәхнәсенә менгән.

Спектакльдә ике төп герой – Хан һәм Шагыйрь. Бер-берсенә шулкадәр охшаган, әмма икесе ике дөньядан булган бу кешеләрне хәтта иң якыннары да аера алмый. Бирдебәк хан һәм шагыйрь Әхмәд Казанлы ролендә – Татарстанның атказанган артисты Рамил Вәҗиев. Мондый образларда күрергә күнегелмәгән булса да, ул ханга әверелгән шагыйрьнең эчке кичерешләрен оста күрсәтә. Герое күңелендәге үзгәрешләрнең никадәр каршылыклы һәм газаплы булуын ача алган ул.

– Ни өчен кеше мәңгелеккә дәгъва кыла? Ни өчен ул үлгәннән соң да юкка чыгарга теләми? Ходай Тәгалә һәркемне дә тигез яраттым дигән, ә нәрсә соң ул – тигезлек? Тигезлек бармы ул? Әллә үлем генә кешеләрне тигезлиме? Кеше тырышып-тырмашып яшәргә тиешме, әллә язмышына буйсынсынмы? Кеше кылган гамәлләре өчен җавап бирергә тиешме? Спектакльдә әнә шул катлаулы һәм һәркемне дә борчый торган сорауларга җавап эзлибез, – ди Рамил Вәҗиев.

Хакимияткә килгән кеше үзгәрәме? Яктылык һәм караңгылык, туганлык-кардәшлек, көнчелек-мәкер, гаделлек-тугрылык һәм башка бик күп темалар ачыла әлеге спектакльдә. «Гаделлек өчен үләргә дә була», – дип җан аткан романтик шагыйрь, хан тәхетенә утыргач, җинаять юлына баса. Тәхет тирәсендә туганлык юк шул. Хакимлеген саклап калу өчен, бөтен нәселен юк иттерә ул. Ләкин кан кою белән сакланган түрәлек аңа бәхет китерми…

«Игезәк» спектаклендәге фәлсәфи һәм сәяси фикерләр Зәйдулланың үткен теле белән яңгырый.

– Ркаилне театрда бик яраталар. Аның бездә күп кенә пьесалары куелды. Иң якты эз калдырганы «Үлеп яратты» спектакле бөек шәхесләр, репрессияләр турында булса, бу юлы Ркаил, күпкырлы шәхес буларак, гайре табигый хәлне алып, шуның турында пьеса яза. Бу, әлбәттә, аллегорияләр белән бара, – ди Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Илдар Хәйруллин. – Хакимлек иткәндә кеше нинди үзгәрешләр кичерә? Безнең өчен бик кызыклы материал бу, чөнки адәм баласы үзгәрми. Мең ел элек тә шулай ук яратканнар, хыянәт иткәннәр, дәрәҗәгә үрмәләгәннәр. Элек тә шулай булган, бүген дә. Безнең җәмгыять өчен бик кирәкле һәм актуаль проблемаларны күтәргән спектакль бу.

Спектакльдә Бирдебәк ханның көчсезләнү хәлен дә күрәбез: туганы Танышбәкне үтергәч, ауган тәхетне күтәреп урынына куймакчы була, тик никадәр тырышса да, булдыра алмый. Бу үзе генә дә ни тора бит!

Тәхетне күтәреп кую гына түгел, югары түрә булып, гадел хөкем итү дә авыр икән…

Спектакльдәге декорацияләр (гади генә булса да) һәм костюмнары ошады. Алар нәкъ шул чорны җанландыра кебек. Музыкаль бизәлеш тә аерым игътибарга лаек. Ул Алтын Урда темасына эпик яңгыраш, көч өсти. Бирдебәк ханның авыр уйларын, эчке кичерешләрен тасвирлый.

Төп сорауга җавап бармы соң? Әйе, хакимлек кешене үзгәртә, боза… Спектакльдәге цитата белән әйтсәк, тәхеттә карасөяк тә ак булып күренә.

Шулай итеп, Камал театры сәхнәсендә янә актуаль – тигезлек, туганлык, гаделлек кебек мөһим гомумкешелек проблемалары күтәрелде. Тарихи риваятьләргә нигезләнеп язылган Алтын Урда чоры вакыйгалары хәзерге чор рухы белән тыгыз бәйләнештә күрсәтелә. Урта гасырлар чигендә барган вакыйгалар бүгенгә хас яңгыраш ала. Ял итәргә, күңел күтәрергә теләүчеләр өчен түгел бу спектакль. Тирән фикер, фәлсәфә эзләү өчен. Спектакльнең финалы да каршылыклы уйларга китерә, аны һәркем үзенчә аңлый.

Ләйсән САФИНА

ГАРМУНЧЫ МУЛЛА

Соклану

Әй, бу нарат урманының һавасы! Күкрәк тутырып бер суласаң, кем әйтмешли, яшиселәр килеп китә. Борынны, үпкәнең һәр күзәнәген рәхәт итеп кытыклаган сагыз исенә хушланып ятканда, колакка гармун тавышы ишетелде. Шифаханәләрдә кичен гармун уйнаганнарын күргән дә, ишеткән дә юк иде. Җитмәсә, без яшь чакта җырлап урам әйләнгән көйләрне сыздыра бу. Кушылып җырлыйсы гына килә бит!

Тыңлап яттым, яттым да, тукта әле, кичләрен кем шулай моңлана икән, төшеп карыйм әле, дип бүлмәдән чыктым. Ишекне ябып өлгермәдем, гармун тавышы тынды. Шулай да бер кузгалгач, кем уйнаганын белешим дип аскы катка төштем. Администратор ханым: «Беренче каттагы номерның балконында уйнадылар. Түбәтәйле бер абзый ул», – диде. Түбәтәйле гармунчы ул көнне балконга бүтән чыкмады. Ә икенче көнне нәкъ шул ук вакытта кунакханә каршындагы мәйданчыкта яңгырады гармун тавышы. Яшь чакта үзе дә гармун тартып, «каравыл кычкырып» җырлап, авыл урамнарын әйләнгән Риман ни җаны белән түзеп бүлмәдә утырсын инде! Тиз-тиз киенеп, урамга чыктым. Түбәтәйле, җыйнак кына сакал-мыек җибәргән гармунчыны инде биш-алты хатын-кыз урап алган иде. Бер көйне уйнап бетерә, аңа: «Хәзрәт, фәлән көйне уйна, төгән көйне сыздыр әле!» – дип заказ бирә торалар, ә ул ялындырмый. Тик кайчак җырларның сүзләрен белмәүчеләрне шелтәләп ала. «Кызлар, иртәгә тагын чыгам, сүзләрен яттан белмәсәгез, кәгазьгә язып килегез!» – ди. Кызлар алдында егетлегемне күрсәтәсе килеп китте, хәзрәт уйнаганга үзем җырлый башладым, миңа кызлар кушылды. Кызу көйләргә бии-бии җырладылар алар.

Шулай итеп шифаханәдә татар мәйданчыгы барлыкка килде. Ял итүчеләр милли яктан шактый чуар булса да, һәркөнне кичен татарча җырлап-биеп алуны гаеп итүче булмады.

Мин хатын-кызларның гармунчыга «хәзрәт» дип дәшүләренә бераз сәерсенгән идем. Ул, чыннан да, Теләче районының Бичер авылы мулласы булып чыкты. Исеме – Фәннур, фамилиясе – Галимҗанов. Колхозда нинди һөнәр бар – яшь чагында барын да татып караган Фәннур. Әллә ничә тапкыр үлемнән калган. Дингә кереп китүе, намазга басуы, бәлки, нәкъ менә шул фаҗигале вакыйгаларга бәйледер. Бу хакта ул ачыктан-ачык кистереп әйтми, илаһи көч барлыгы үзеннән-үзе күңелгә керде, ди. Үзлегеннән Коръән серләрен өйрәнә башлый.

Инде мин менә ничә мәртәбә «светский» муллалар белән очрашам. Алар авыл тормышының тоткасы кебек. Аяк бөкләп, намазлык өстендә генә утырмыйлар, димәкче булам. Фәннур хәзрәт халыкка сүз белән дә, эш белән дә булыша, авыл сәхнәсен дә үз итә. Спектакль-концертларда, төрле бәйрәмнәрдә катнаша.

– Гармун уйнап йөрүеңне өнәп бетермәүчеләр юкмы? – дип сораган идем.

Киресенчә: «Ник гармуныңны алып килмәдең, хәзрәт?» – диләр икән моңа. Быел үзләрендә узган «Уйнагыз, гармуннар!» бәйгесендә III урынны биргәннәр. 3 нче класстан бирле кулыннан гармун төшкәне юк икән Фәннурның. Үзе гади генә итеп: «Кешене матур җырлар, матур көйләр белән дә тәрбияләп була», – ди.

Без кичке аштан соң гел уйнап-җырлап утыра башладык. Ә бер көнне хәзрәт шифаханә клубында концерт куйган. Үзе генә түгел, әлбәттә. Ял итүчеләр арасында җыр-көйгә һәвәс кешеләрне табып, концерт бригадасы оештырып, халыкны ял иттергән. Әйтүенчә, концерт ике сәгать тирәсе барган.

Мин хәзрәтне озата алмадым, чөнки, көтмәгәндә-уйламаганда, бер көнгә иртәрәк кайтып киткән иде ул. Авылга балалары, оныклары кунакка кайткан булган, аларны күрми калам, дип курыккан.

Өч баласы, сигез оныгы бар Фәннур хәзрәтнең. Алар кунакка кайтса, бабалары янында мәш киләләр, оныклары гармунның әле бер, әле икенче ягына ябыша, көй чыгарырга тырыша икән. Тик алар бик кечкенә шул әле, араларында, бәлки, бабалары кебек гармунга мөкиббәннәр дә булмас. Аның каравы, хәзрәт әйтмешли, җыр-көй аша матур тәрбия алырлар, матурлыкны күрергә өйрәнерләр.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Аш-су

tatar-inform.ru

ЮНЫС ӘХМӘТҖАНОВ ЭЗЛӘРЕННӘН

Пешекчеләр генә түгел! Менә инде алтынчы тапкыр башкалада Юныс Әхмәтҗанов исемендәге яшь аш-су осталары халыкара турниры уза. Легендар кулинар, татар ашларының атасы истәлегенә оештырылган турнирда быел меңгә якын пешекче үзара көч сынашты. Җиңүчеләрне Бәшир Рәмиев исемендәге IT паркта бүләкләделәр.

Шунысы игътибарга лаек: быел бәйге халыкара статуска ия булды. Анда Казахстаннан да яшь пешекчеләр катнашты. Әле алай гына да түгел, сигез финалистның икесе – кардәш республикадан. Бу бәйгенең үзебезнең илдә генә түгел, хәтта чит илләрдә дә популяр булуы, төрле милләт вәкилләренең татар ашлары белән кызыксынуы турында сөйли. Турнирның төп максаты да шул бит: Россия төбәкләрендә һәм чит илләрдә яшәүче халыкларны җәлеп итеп, милли аш-сулар аша шул халыкларның тарихы һәм мәдәнияте белән таныштыру.

– Пешекче һөнәре – иң икмәкле һөнәр. Әмма хәзерге вакытта без кадрлар кытлыгын күзәтәбез. Безнең теләк – мондый чаралар аша пешекче һөнәрен популярлаштыру, – диде тантаналы чарада Татарстан рестораторлары һәм отельерлары ассоциациясе президенты Зөфәр Гаязов.

Финалга узган егетләр һәм кызлар үзләре уйлап чыгарган рецепт буенча ризык әзерләргә тиеш иде. Һәрбер катнашучының ярдәм кулы сузарга әзер торган остазы булган. Тәҗрибәле пешекчеләр файдалы киңәшләре белән уртаклашкан. Хәер, яшьләр үзләре дә кимен куймый. Финалистларның барысы да бүген үк су-шеф булырлык, ди жюри әгъзасы, Казандагы бер ресторанның шеф-повары Рөстәм Рәхимов та.

– Алар гади пешекчеләр генә түгел, ә инде җитәкчелек тәҗрибәсе булган зур профессионаллар. Без аларның кайберләрен стажировкага да алдык. Яшьләр бик талантлы, – дип сөйләде аш-су остасы.

Жюрига иң осталарны сайлап алу җиңел булмагандыр. Чөнки күренеп тора: һәрберсе тырышып әзерләнгән, җиңү өчен бар көчен куйган. Тик Гран-при берәү генә һәм аңа Югары Ослан районы кызы Зилә Әҗмуханова лаек булды.

– Җиңүне бөтенләй көтмәгән идем, хәтта сүзсез калдым. Остазыма зур рәхмәт. Моның кадәргә барып җитәрмен дип уйламадым да, минем өчен катнашу – үзе зур бәхет. Бу уңыш – тырышлык, иренмәү нәтиҗәседер. Бу – беренчедән, әти-әнием тәрбиясе, икенчедән, остазым тырышлыгы дип уйлыйм. Аларга бик зур рәхмәт, – дип уртаклашты җиңүче тәэсирләре белән.

21 яшьлек Зилә – авылда туып-үскән гап-гади татар кызы. Казан сәүдә-икътисад техникумында укый.

– Авыл кешесенең эшен тавык та чүпләп бетерми дигән әйтем бар. Әти-әни эштә булгач, без, балалар, өйдә хуҗа булып кала идек. Иң беренче тапкыр 4–5 яшьләр тирәсендә пешергәнмендер. Беренче ризыгым кыздырган бәрәңге булды. Аннан модага пицца керде, аны пешереп, күрше әби белән бабайны да сыйлый идек, – дип искә алды Зилә.

– Милли ризыклардан чәкчәк, гөбәдия, кыстыбый пешерергә яратсам да, ит бәлешен күбрәк үз итәм. Юныс Әхмәтҗанов – безнең кебек яшь пешекчеләргә маяк ул. Татар ашларын югары дәрәҗәгә күтәргән бөек шәхес.

Зилә киләчәккә хыяллары белән дә уртаклашты:

– Киләчәктә үз эшемне булдырырга исәбем бар. Ә хәзергә укырга, тәмле ризыклар пешерергә, яңа үрләр яуларга…

УКУЧЫ СҮЗЕ

Үз юлым

Тәрәз буйлап тәгәрәгән тамчы,
Битләр буйлап ачы яшь юлы,
Йолдыз эзе төнге күкләр аша,
Зур елгага тоташ су юлы.

Күңелемдә – яра, тәндә – яра...
Үткән еллар шулай юл сала.
Үз кайгым да, ятлар бәхете дә, –
Җанда тирән булып эз кала.

Үз юлыма меңәр башка сукмак
Сизелмичә килеп тоташа.
Ялгыз яши алмый бер кеше дә,
Атлый юлдан каршылыклар аша.

Кире кайтып сукмак башларыма,
Үтәр булсам юлны яңадан,
Юк, сайламас идем башка юллар,
Үземнеке булса авырдан.

Рәфинә МӘННАНОВА

wallpaperflare.com

БИК РӘХӘТ БУЛДЫ

Көз җиту белән, суыклар башлангач, кайчан җылы бирерләр икән дип, куркып көтә идек. Ә быел Татарстан Рәисе фатирларыбызны вакытында җылытырга әмер бирде. Бик рәхәт булды. Шуңа күрә Рөстәм Нургали улы Миңнехановка иксез-чиксез рәхмәтләребезне юллыйбыз. Эшендә һәм тормышында гел югары уңышларга ирешсен, исән-сау булсын. Без, республика халкы, аны бик яратабыз, хөрмәт итәбез.

Кәрибә ГОМӘРОВА

dreamstime.com

ГОМЕР БИШТӘРЕ

Бәләкәйдән, күкнең җир белән тар гына сызык булып тоташкан җиренә барып, аякларны салындырып утырасы килде. Яңгыр коеп яуганда, күк йөзендә төрле төсләр белән балкыган салават күперенең астыннан чыгарга хыялландым. Бәхетне үз кулларым белән тотып карыйсым килде...

Офыкларга барып җитәм дип, күпме еллар узды, күпме башмак тузды, барып җитеп булмады. Салават күперенә карап бара-бара, күпме кәпәч төшеп калды, күпме кием чыланды. Киемнәр кибүгә, салават күпере югалды. Бәхетне танымыйм бит әле. Аны эзләп чыккан юлда бер хәбәр килде: «Юлыңда очраганнарны барысын да җый, бәхет шулар арасында булыр!»

Очраган мәшәкатьләрне-борчуларны, уңышларны-югалтуларны, шатлык-кайгыларны, өмет-хыялларны, йокысыз төннәрне, арулы көннәрне биштәремә җыя бардым. Биштәр авырлыгыннан аяклар салмакланды, егет чактагы төз гәүдә алгарак сөрлекте. Биштәр һаман тулмый да тулмый. Һаман җыя барам. Туганнар, балалар, оныклар, киленнәр, кияүләр, кодалар-кодагыйлар өстәлде. Кайчак буш вакытларымда, кеше күрмәгәндә биштәремне актарам. Беләм, бәхет шунда, әмма тотып кына карый алмыйм...

Сак кына итеп биштәремне иңнәремә салам да гомер юлымны дәвам итәм. Тишелә генә күрмәсен, түгелеп-чәчелеп әрәм-шәрәм булмасын. Бәхетем төшеп калмасын.

Әнвәр СӘРВӘРОВ

Бәгырь ташларын эретүче

Сабый чакта, бишектә ятканда, әле үзеңне аңламаганда, син инде әниеңнең ягымлы тавышын таныйсың, күңел җылысын тоясың, аның җырларына изрәп йоклыйсың, матур сүзләренә шатланасың, көләсең. Туганнан алып, әниләребез һәрчак янәшәдә: «әннә» дип телебез ачыла, беренче адымнарыбызны күреп, газиз әниләребез сөенә, мәктәпкә озатучы да, каршы алучы да ул! Чирләп китсәң, синең урыныңа үзе авырырга әзер торучы, Аллаһтан сиңа ярдәм сораучы да – ул! Безнең иң якын киңәшчебез дә, сердәшчебез дә, елаганда, сүз белән бәгырь ташларын эретүче дә, хәсрәт килгәндә, җиңеләйтүче дә, шатлык килгәндә, синнән дә артыграк сөенүче дә – ул! Беркемгә сиздермәгән серләреңне күзеңнән укучы, шунда ук аңлаучы. Бөтен дөнья синнән баш тартканда да, синнән йөз чөермәүче. Соңгы сулышында да синең исемеңне атаучы, хәер-фатыйхасын биреп калырга тырышучы ул – әни.

Әнием белән үткәргән көннәрем – иң кадерле, якты, матур, онытылмас хатирәләр. Балачагымның, әнием белән бергә яшәгән гомеремнең хатирәсе йомгагын сүтәм, хәтер дәфтәрен актарам. Кайсы көн турында языйм икән: балачакта әнием белән урман-кырларга җиләк-җимеш җыярга йөргән чакларымнымы, мал-туарга печән чапкан җәйге матур көннәрнеме, кышкы кичләрдә күрше апалар кереп, җеп эрләп, күңелле итеп кич утыруларнымы, колхоз басуларында, ындыр табагында эшләп йөргән вакытларнымы, әллә инде укып йөргән чорны – авылга ял көннәрендә һәм каникул вакытларында кайтканда әниемнең сагынып каршы алган, моңсуланып озатып калган чакларнымы? Саный китсәң, ул көннәр турында калын бер китап язып булыр иде.

Аллаһы Тәгалә әниемне сабыр, йомшак табигатьле, киң күңелле, ачык йөзле, бик тә ягымлы, көчле рухлы, хисчән итеп яраткан. Әткәебез вафат булганда, аңа – 39 яшь, олы абыйга – 16, сеңлемә 6 яшь иде. Әнием сынаулардан торган язмышка бирешмичә, без – биш баланы берүзе тәрбияләп үстерде. Зур кайгы килгәндә дә сабыр булды. Үзе исән чагында 3 баласын югалту ачысын да татырга туры килде аңа. Әмма беркайчан да төшенкелеккә бирелмәде. Замана белән бергә атлады, яңалыкка омтылды. Газета-журналлар укырга, радио тыңларга, телевизор карарга да вакыт таба иде, дини йолаларны үтәп, бәйрәм ашларына туганнарны җыеп, Сабан туенда кешеләр белән аралашып, кунак итәргә ярата иде. Аның мичтә пешергән коймак-тәбикмәкләре, бәлеш-өчпочмаклары, җиләк-җимеш кайнатмалары, какларының, әзерләгән рызыкларының тәме! Башка берәүнеке дә әниемнеке кебек була алмас. Аның тормышны, хезмәтне яратуын, зирәклеген, көчле рухлы, акыллы, сабыр, киң күңелле булуын сокланып искә алам.

Әниемә 85 яшь тулган көнне Коръән ашы үткәрәбез: туган йортыбыз гөрләп тора, әниемнең йөзе тулган айдай балкый, хәрәкәтләре җитез, күңеле сөенеч-шатлыктан тулган, туганнар, балалар, оныклар, күршеләр, авылдашлар җыелган – нинди матур мәҗлес! Аллаһ биргән сый-нигъмәт тулы өстәл янына утырышабыз. Коръән укылды. Әнием мөнәҗәт укый, безнең күзләрдә – яшь. Фото-видеоларны карап утырганда, әниемнең, соңгы тапкыр безне бер табын янына җыеп, безнең белән саубуллашуын, хәер-фатыйхасын калдыруын хәзер генә аңладым.

Рәхмәт, әнием, барысы өчен дә, рәнҗеткән булсам, гафу ит! Искә алып язган язмамны хәер-дога итеп кабул ит!

Гөлфинә ӘХМӘТҖАНОВА

Миңа нәрсә җитми?

Көннәрнең берсендә алган акчамның аз булуын һәм башка вариантлар эзләргә кирәклеген аңладым. Телевизордан һәм гайбәтләрдән баш тарттым, мондый әйберләргә вакытым юк чөнки. Мин интернетта акча эшли башладым.

Һәр яңалык бик авырлык белән керә. Миңа да бу җиңел булмады. Якыннарымның кайберләре мине аңламады. «Сиңа нәрсә җитми?» – диделәр, минем бизнеска ышанмадылар, дусларым туктатырга тырышты. Артымда үзем турында күңелсез сүзләр ишеттем. Ләкин шул ук вакытта мин чын акча эшләүчеләрне күрдем һәм үземнең дә шулай булуымны теләдем.

Мин өйдә диванда кырын ятып та эшлим. Иң мөһиме, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында ярдәм итәргә әзер торучы искиткеч хезмәттәшләрем һәм дусларым бар. Олы яшьтә булуыма карамастан, өр-яңа тормышка кереп киттем. Һәм миңа биредә бик ошый. Бәлки, гомерем буе нәрсәгәдер өйрәнергә тырышуым да ярдәм итә торгандыр. Әгәр сез дә теләсәгез, эзлекле рәвештә эшләргә әзер булсагыз, барысын да үзгәртергә мөмкин дип ышанам.

Фәния НАСЫЙХОВА

Уйлы күңел уйлана

Кышка кереп барыш

Башка елларны шушы вакыт җитсә, ирем Илгиз: «Кышларны исән-сау чыгып булырмы?» – димичә калмый иде. Салкын, карлы кышны яратмавы түгел, кырык елга якын гел юлда йөргән кешенең кышка борчылып керүе табигый кебек. Бер көн түзмәдем: «Быел бер дә теге җөмләңне кабатламыйсың әле, кыш җиткәнен сизми калдың бугай», – дим. Көлемсерәде.

Дөрестән дә, быел апрельдән октябрь башына кадәр сузылган җәйдән санаулы көн эчендә кышкы күчеш чорына «сикердек» кенә ләбаса. Иязнерлек тә, сизәрлек тә булмады. Гел чалт аяз, кояшлы, җылы көннәргә тәмам күнегеп беткән булганбыз, ахры. Берничә көн кояш күренми башлауга инде үзен сагынып та өлгердек. «Кая китте кояшлы көннәр?» – дигән кешеләргә мин үзем: «Инде җәй буе без зарланганнарны аңлаган булса, кояш безгә бөтенләй дә карамас иде», – дим. Килешәләр. Һәр нәрсә чамасы белән һәм үз вакытында булганда гына кадерле шул.

Без ел да, быел табигатьтә күп нәрсә үзгә булды, дияргә яратабыз. Ул, чыннан да, шулай. Тикмәгә генә табигатьтә ел елга охшамый, димиләрдер. Бу сүзләрдә хаклык барлыгына ышану өчен соңгы ике елны гына чагыштырып карау да җитә.Үткән ел әнә: «Башта язны, аннан җәйне күтеп үткәрдек, августта тоташ булган челләдән шактый туксырган идек, сентябрьдә үк башланган төссез көннәр дә күпкә китте кебек. Бер эшне дә иркенләп, тәмләп, үз вакытында тынычлап эшләп булмады. Язын һәм көзен авылда эш аеруча күп була. Аларның һәркайсының үз чираты бар. Быел исә язын да, көзен дә әлеге чиратлар буталды. Язы да, көзе дә бер чама килде шул. Шуңа күрә ай буена дип планлаштырылган эшләрне аяз торган санаулы көн эчендә эшләп өлгерергә кирәк булды. Язгысында әле, әйдә, җәй озын, эшләрбез, дип юансак, хәзер инде, менә-менә суыта, туңдыра, дип, ашыгырга туры килә. Безгә генәме, күмәк хуҗалыкларга да мондый язлар-көзләрдә шактый кыенга туры килә. Аларда да бит барысын да үз вакытында эшләргә кирәк. Кайбер елларда инде октябрь ахырына барлык техниканы кышкы саклауга куеп өлгерсәләр, быел әле басуларда эш бетмәде: орлыкка дигән кукуруз-рапсның өлгерүенә кояшы, җылысы җитмәде, алар соңарды, җир эшкәртүләр дә тоткарланды. Бүген техникалар куәтле дисәң дә, һава шартлары мөмкинлек бирмәгәндә алар да берни эшли алмый шул», – дип язганбыз. Быел ул исәптән авыл кешесенә бөтенесен вакытында эшләп бетерергә көне дә, җылысы да – дымнан, яңгырдан кала барысы да җитәрлек булды.

Беренче салкыннарга кадәр кырау да төшмәде. Шул сәбәпле чәчәкләр дә соң көзгә кадәр искитмәле булып утырды. Күбебез аларны, җыярга вакыт җитте инде, – дип кенә җәлли-җәлли йолкыды, кисте. Гадәти теплицалардагы соңгы кыяр-помидорларны да шушы көннәрдә генә җыйнап бетерде авыл кешесе. Ачык һавадагылары да җирне эшкәрткәнче кинәнеп үсте. Август ахырларында инде каты кыраулар төшкән чаклар күп була иде. Быелга дигән «норма» июнь уртасында көтмәгәндә төшеп һәм шактый зыян салып, үтәлгән булды, ахры. Көзге кырауларны күрмәдек тә, сизмәдек тә...

Моннан өч ел элек: «Ноябрь уртасында урамда беренче кар ява, матур», – дип язганмын. Ә быел әнә октябрь уртасында бар җир акка күмелде. Дөрес, ул вакытлыча булды. Сынамышлар буенча, кемдер кырык, кемдер алтмыш көннән кар ятачак, дип өметләндерә. Тик өметләр генә бөтенесе дә чынга ашмый. Кызганычка, җәй буе көткән яңгырлар көзен явар әле дигән өметләр дә акланмады. Соңгы яңгырлар җирнең өске катын гына «майлап» киткән икән (шактый яуган кебек тоелса да, бакчага чыгып, көрәкнең очын гына тыгып карасаң да, дымның юклыгы шомландыра). Бөтен өмет җепшек карларда, кар катыш яңгырларда инде. Кышларга тыныч күңел белән керү өчен, авыл кешесенә алары да кирәк шул...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА


Илдар Мөхәммәтҗанов

ИЛАҺИ КӨЧ

Олыгайган ике яшьтәшнең берсе елына ике мәртәбә сәяхәт итеп кайта, ә икенчесе, таякка таянып, көчкә-көчкә диван белән өстәл арасында йөреп тора. Җавап бер генә: начар генетика, югары кан басымы, төшенке кәефне, тагын башка бик күп сәбәпләрне сылтау итеп диванда ята бирсәң, чалт аяз беркөнне кулыңа таяк тотасыңны көт тә тор.

Картлык авыруы да оешмаганлыктан, ялкаулыктан, үз табигатеңне аңламаудан, тискәре хисләреңне иярли алмаганнан килә дип уйлыйм. Беренче чиратта тормышыбызда челем тартуга, исерткеч эчемлекләргә, наркотикларга урын булмаска тиеш. Исемлеккә стресс та керә. Бу зәхмәтне дә без чеметеп-чеметеп йота торабыз. Авыр кайгы-хәсрәт турында гына сүз бармый. Эшкә соңга калабыз, автобуста кысынкы, төнге эш – барысы да стресс. Вагы-төяге җыелып бара да депрессиягә китерә. Аннан качып котылып булмый, бары тик көн дәвамында ялкынсынган баш миен тынычландырырга, «энергия капчыгы»н яңартырга гына кирәк. Әлбәттә, сулыш гимнастикасын, йога алымнарын өйрәнер һәм кулланыр өчен теләк тә, вакыт та кирәк. Ә тиз арада безгә су ярдәмгә килә. Талчыккан нервларны тынычландыру өчен, музыка куеп, атнага бер мәртәбә булса да, диңгез тозы салган ваннада ярты сәгать ятып торыгыз. Ул тынычландырып кына калмый, лимфа һәм кан йөрешен яхшырта, физик эштән соң мускулларны йомшарта, буын авыруларын дәвалый. Безгә көннең бер сәгатен булса да үзебез өчен яшәргә кирәк.

Нәрсә ашарга, нәрсә ашамаска икәнлеге турында бөтен интернет тулган. Мин бик күп тәҗрибәләр үткәреп карадым. Бер атна су гына эчеп ач тордым. Шуннан соң капкан бер кашык дөгедән дә тәмлерәк нәрсә юк икән дигән фикергә килгән идем. Баксаң, без теләсә нәрсә ашап, тел рецепторларының тоемлавын бик киметәбез икән.

Соңрак атнага бер тапкыр көн ярым ашамый тора башладым. Аннары япон галиме, Нобель премиясе лауреаты Есинори Осуминың аутофагия алымы буенча 8 сәгать арасында ашап, 15–16 сәгать ач торуның иң кулай булуына инандым. Бу ысул яман шеш авыруларына профилактика буларак та әйбәт диелгән, чөнки ул ач тору арасында күзәнәкләрнең чүп-чардан арынуын исбатлаган. Шунысы да бик рәхәт: ашаган ризыклар эшкәртелеп бетә, эчеңдә берни дә калмый. Гәүдәдә – җиңеллек, эчтә – комфорт. Иң җайлысы кичке алтыда туктап, иртәнге ашны 9–10да ашау. Әгәр эштән кайтып, бик ашыйсыгыз килсә, йокларга ике-өч сәгать кала ашагыз. Ач тору вакыты барыбер 16 сәгать булырга тиеш.

Үзем туйдым, күзем туймады дигәндәй, бүселеп чыкканчы ашауның бер мәгънәсен дә күрмим. Күп ашасаң, киресенчә, йокыга тарта башлый, кеше хәтта исереп киткәндәй була. Учакка утынны аз-азлап салып торсаң, яхшы яна, безгә дә ризыкны аз-азлап салып торырга кирәк. Минем яраткан юмористым Михаил Задорнов: «Иң зыянлы эчемлек – чәй, аның янындагы кәнфит, печенье», – ди иде. Тугыз ай чәй, кофе эчмәдем. Ризык ашаган арада гына чиста су эчәм. Нәтиҗәдә тормышымнан шикәрле әйберләр юк булды, унөч килога ябыктым, аңым ачыкланды, үземне гаять җиңел, рәхәт сизә башладым. Һәм иң кызыгы – тешләрем ап-ак булды.

Шикәрнең кан тамырларына зыяны бик күп. Мөмкин булса, аны рационнан бөтенләй бетерергә, һич булмаса, киметергә иде. Баллы ризыклар исәбенә кура җиләге, күк җиләк, викториядән кала алма, банан, виноград шикелле җимешләр дә керә. Шикәр – организмыбыздагы паразитларның яраткан ризыгы да, шулай ук алар сөт, ак күмәч кебек «күчтәнәч»ләрне яраталар. Бик аңлыйм, нәрсә ашарга соң диярсез? Бар нәрсәне дә ашарга, ләкин чама белән.

Үз-үзебезне сәламәтләндерү механизмнарын Ходай безнең тәнебезгә салган. Аның иң беренчесе – кан. Аның үтеп кермәгән җире юк. Икенчесе – лимфа. Ул – организмның канализация челтәре. Әгәр канны йөртер өчен организмда көчле мотор – йөрәк каралган булса, лимфа йөреше безнең хәрәкәткә бәйле. Фасция – организмда һәр органны урап алган юка элпә. Алар үз максатына ирешсен өчен, бездән хәрәкәт кирәк. Кан капиллярларга кадәр үтеп керсен дисәң, йөгерү, сикерү генә җитми, кул-аякны дерелдәтеп, вибрацияләр тудыру да кирәк. Лимфа йөрешен яхшырту өчен, үз-үзеңне массажлау яхшы. Фасциянең бер урында кыскарып, икенче урында сузылуы аркасында буын авырулары, остеохондроз, сколиоз, төрле башка деформацияләр килеп чыга. Гәүдәдә камиллек булсын өчен, сузылырга кирәк. Аң тынычлыгы өчен – сулыш гимнастикасы, җан сафлыгы өчен – дога, иммунитет өчен – саф һава, кояш нурлары... Болар – гаиләбезнең күркәм гадәтләре. Спорт – тормышымның аерылгысыз өлеше. Озаклап шөгыльләнергә вакытым булмаганда, иң үтемле күнегүләр ясап куям.

Урман, табигать, сусыз яши алмыйм кебек. Җанны да, аңны да сәламәтләндерүче илаһи көч бар аларда. Сәламәтлекне сатып алып булмый. Ул – матурлыкның нигезе, Ходай биргән нигъмәтләрнең иң олысы. Шуңа күрә аны сакларга һәм ныгытырга кирәк.

Фирдәүсә БИКМӘТОВА



ХА-ХА-ХАНӘ



Шушы урында көләсе

Мач әйткән!

Салават ФӘТХЕТДИНОВ, җырчы:
– Без – әниләрне хөрмәт итеп, алардан куркып яшәүче соңгы буын. Һәм без – балаларыбыз көен көйләп, алардан куркып яшәүче беренче буын.

7 сорауга – 7 җавап

1 **– Проект менеджеры кем ул?**
– Эшкә тугыз хатынны алсаң, алар сиңа бер айдан бала таба алачак, дип уйлаучы.

2 **– Камиллеккә ничек якынаерга?**
– Минем янга бас.

3 **– Хатын-кызлар ник һәрвакыт соңга кала?**
– Аларның сәгатендә 100 минут.

4 **– Ясалма интеллект, әйт әле миңа, башта сүз булганмы, әллә эш булганмы?**
– Башта ташларга уеп ясалган мэмнар булган.

5 **– Ни өчен таксист юл буе берни дәшмәде?**
– Ахырдан ниндидер бер акыллы сүз әйтеп ку яр өчен көч җыйды бугай.

6 **– Тузан суырткыч робот сыман яшисем килә, дигәндә нәрсәне күз алдында тот тың?**
– Килеп бәрелдең, хатаңны аңладың, берни булмагандай дәлше киттең.

7 **– Ни өчен дөреслекнең төбенә төшеп җиту куркыныч?**
– Чөнки төбенә төшеп җиткәч, дөреслек синең өстеңә ишелергә мөмкин.



Вәсвәсәле фәлсәфә

Тиздән инде ахырзаман, ә син һаман әти-әниемнең йөзенә кызыллык китермим дип яшисең.

⌄⌄⌄

Бу киноны юләрләр өчен диләр, ә миңа ошады.

⌄⌄⌄

Әгәр минем бер минут буш вакытым барлыкка килгән икән, димәк, мин нәрсәнедер эшләргә онытканмын.

⌄⌄⌄

Тиздән үзенең югары уку йортының исемен дөрес итеп әйтә алган кешене дә ректор итеп куячаклар.

⌄⌄⌄

Кемнедер тормыш күп акча, танылу һәм дәрәҗәле вазыйфалар белән сыный. Ә мине акчасызлык һәм явыз хатын белән сынады.

⌄⌄⌄

Кибеткә ипи алырга гына чыгып, бары тик ипи алып кайткан кешеләр бармы бу дөньяда?

⌄⌄⌄

Сакаллы мәзәк, дисез... «Мәзәк» сүзе ул инде үзе үк сакаллы.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ДА

Алданрак килгән туган көн

Мин «Ватаным Татарстан» газетасында җаваплы секретарь урынбасары булып эшләдем. Минем эшем бер көнне газетаның макетын сызып, икенче көнне шул сызылган макет ярдәмендә цехта, типографиядә газета чыгару иде.

Бер көнне хезмәттәшем Гаҗилә апайга өйләрендә булышырга туры килде дә, макетымны сыза алмый калдым. Икенче көнне эштә бөтенебез иртәнге планеркага җыелдык. Ул вакыттагы баш мөхәррир Мөнир абый Әһлиуллин миңа сызган макетымны күрсәтергә кушты. Мин тиз генә тырыша-ашыга булмаган макетымны сызарга тотындым. Шунда миңа Мөнир абый: «Эшеңне эшләмәгәнсең, премияңне кисәм!» – диде.

Бу 23 февраль – Совет армиясе көне иде. Үткән гасырның 90 нчы елларында редакциядә бәйрәмнәр бик күңелле, берничә көн буена гөрләп, шаулап үтә иде. Кичкә таба хезмәттәшләрем белән бәйрәм табынына җыелдык, әзрәк «төшереп» алгач, мин редактор янына киттем: «Мөнир абый, син мине ярата идең, бүген бит минем туган көнем, нишләргә инде хәзер?!» – дидем аптырап, үзем дә нәрсә әйткәнемне белмичә. Мөнир абый шунда кисәк кенә үзгәреп китте: «Зөлфәт, тукта әле, кая, тартырга бир әле, әйдә, минем бүлмәгә кереп сөйләшик, мин дә кызып киткәнмен, ахры, кемдә дә була инде ул андый хәлләр, нишлисең!» – дип, мине үзе артыннан ияртте. Редактор бүлмәсеннән инде без Мөнир абый белән дуслашып, аңлашып, туганлашып чыктык.

Мин бит әле үзем эшләгән елларда редакциянең гармунчысы да булдым. Ә Мөнир абый – гармун моңнарын, халык җырларын, иҗат кешеләрен яратучы, нечкә, яхшы күңелле кеше. Нинди авыр вакытларда да Мөнир абый ташламады, гел ярдәм кулын сузып, егылсаң, тартып торгызып, аякка бастыра иде шул, рәхмәт яугыры!

Автор шаржы

Көтелмәгән табыш

Хезмәттәшем Равил Гатауллин белән «Ватаным Татарстан»да 27 ел бер бүлмәдә эшләдек. Равил – бик пөхтә, чиста, саф күңелле, бик ярдәмчел, яхшы кеше. Без аның белән, шаяртып, бер-беребезгә этлек эшләп алырга ярата идек. Миннән аңа күп эләкте инде. Равил беркайчан да үпкәләмәде, ачу тотып йөрмәде.

Бервакыт безнең редакциядә ремонт эшләре башланды. Кем әйтмешли, бүлмәләрдә эт баш, сыер аяк. Карыйм, Равил бакчасына барырга әзерләнә, ике зур пакетны нәрсәләрдер белән шыплап, дыңгычлап тутырып куйган. Ул каядыр чыгып киткән арада, мин ялт кына, авыр, тузан басып киткән бер зур иске телефонны Равилнең пакетына күренмәслек итеп тыгып та куйдым. Күпмедер вакыттан соң тәрәзәдән карасам, хезмәттәшем урамда теге авыр пакетны хатынының кулына тоттырды. Бакчасына баргач, пакетыннан теге ямьсез телефон килеп чыккач, нәрсә булганын белмим, Равил һәрвакыттагыча бернәрсә дә сиздермәде.

Бер-ике көннән мин дә, өйгә кайтып, хатын алдында сумкамны ачып җибәргән идем, шуннан ялтырап, бер резин әйбер килеп чыкмасынмы! Нинди резин әйбер икәнен аңлагансыздыр инде. Ну әләкте инде хатыннан, малай, барыбер түздем бит! Мин дә бу турыда Равилгә сиздермәдем тәки, үзе шикелле сер бирмәдем.

Конверт хәйләсе

«Ватаным Татарстан»да Мәгъсүмә апай Гарипова тәрҗемә бүлегендә эшләде. Тыйнак, күркәм, бик мәрхәмәтле, матур ханым иде. Кулыннан килгәнчә ул һәрбер кешегә ярдәм итәргә тырышты, без аны бик ярата идек.

Шулай эшләп йөри торгач, безнең кесәләрдә акча бетеп китә иде. Инде нишләргә, получкага кадәр кемнән генә акча сорап торырга дип баш вата башлый идек. Шунда безнең искә изге күңелле Мәгъсүмә апабыз килеп төшә иде. Без әле Мәгъсүмә апайның күңелен яулап алырга бер төрле җай да уйлап чыгардык.

Янына килеп басабыз да сокланган кыяфәт белән: «Әбәү, Мәгъсүмә апай, синең бүген причёскаң бигрәк матур, карап туймаслык булган бит бу!» – дип хезмәттәшебезне мактап җибәрәбез. Мәгъсүмә апабыз аптырап карап тора да шунда ук елмаеп та җибәрә, чәчләрен рәтләп куйгандай итә иде. Шуннан әзрәк уйланып тора да: «Аңладым, сиңа тагын акча кирәктер инде, әнә теге өстәл тартмасыннан ак тышлы конвертны алып бир әле!» – ди иде. Без беләбез: ул конвертта һәрвакыт акча була, ул аны нигәдер яшереп тә куймый иде. Кирәкле акчаны әләктергәч, хезмәттәшебез яныннан рәхмәтләребезне әйтеп, тиз генә юкка чыгу ягын карый идек. Мәгъсүмә апабыз лаеклы ялга чыгып, эштән киткәч, и сагындык та инде үзен!

Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН

Аерылмагыз, аерылмагыз...

Хатын-кызлар, иregезне мактагыз, әмма арттырып җибәрмәгез. «Син – иң яхшы ир», – дип әйткәннән соң: «Мин белгәннәре арасында», – дип өстәгез.

***

Яшь кызның кәефе уйный, ә хатынның – кан басымы.

***

– Ике ел җавап бирмәгәнем өчен гафу ит, кәефем начар иде.

***

Кызлар хәзер инде принц көтми. Бераз кешегә охшаса, шул җиткән, ди.

***

– Ярар, син хаклы, гафу үтенүеңне көтәм.

***

– Элек алай ачуымны китерми идең бит син!
– Ояла идем.

***

Кичә күрәзәчегә барып, элекке хатыныма берәр хәчтерүш теләдем. Бүген элеккеге хатыным шалтырата. Яратам, ди, яңадан бергә булыйк, ди.



***

– Ял көннәрне хатыным белән бары тик инглизчә генә сөйләшергә сүз куештык.
– Шуннан?
– Ике көн сөйләшмәдек.

***

Кызлар акыллы егетләрне ярата. Мәсәлән, акчасы күп икән, димәк, ул акыллы бит инде.

***

– Бераз югалып тордым, кияүгә чыгып алдым.

***

– Син мине яратасыңмы?
– Бик, бик, бик авыр сорау бу.

***

– Хәтерлисеңме, биш ел элек син миңа: «Син – бик сәер хатын», – дигән идең.
– Бәлки, әйткәнмендер дә.
– Син нәрсәне күз алдында тоттың?

***

– Гафу, әмма мин җитди мөнәсәбәтләргә әле әзер түгел, миңа нибары 30 гына яшь.

***

Язылышу таныклыгыңа колагыңны куеп тыңлап карасаң, яшьлек елларыңның мышык-мышык елаганын ишетерсең.

Погонлы юмор

Командир хәрби часть буенча бара:
– Ефрейтор! Нишләп торасың монда?
– Эскәмияне саклыйм.
– Ә ник саклыйсың аны?
– Белмим. Миңа кадәр Фәләнев саклады.
– Бир әле Фәләнев телефонын, шалтыратыйм үзенә. Ало! Фәләнев! Ник сакладың син бу эскәмияне?
– Төгәнев сакларга кушты, иптәш командир! Чөнки миңа кадәр Төгәнев саклаган иде.
– Тәк. Ало, Төгәнев? Ник сакладың бу эскәмияне?

Шулай итеп, командир, мәсьәләнең очына чыгарга тырышып, унлап кешегә шалтырата. Баксаң, бу эскәмияне инде 50 еллап саклыйлар икән. Һәм, ниһать, чылбыр 90 яшьлек хәрби ветеранга китереп чыгара. Командир әлеге бабайга эскәмия турында итагатьле итеп кенә сорау бирә һәм көтелмәгән җавап ишетә:
– Ул эскәмиянең буявы һаман кипмәгәнмени әле?



Әз-мәз мәзәк



Башта берәр квест уйнарга җыенган идек, аннары дәүләт оешмасына белешмә-справка алырга киттек.

⌄⌄⌄

– Руслан, әйдә, ресторанга барабыз.
– Ләйсән, мин бит өйләнгән.
– Ой, җәлләп куйдым, әйдә, ашатам.

⌄⌄⌄

Кичә киноны паузага куеп, үземә тәмле итеп мәртүшкәле чәй ясадым. Шуның өчен бүген кинотеатрдагы эшемнән кудылар.

⌄⌄⌄

– Диңгезгә ничек барып кайттың? Кызлар белән таныштыңмы?
– Юк.
– Ник алай?
– Алар йә ирләре белән, йә оныклары белән ял итә.

⌄⌄⌄

«Борчылма», – диләр миңа кайвакыт. «Кара әле, шәп фикер бит бу», – дип уйлап куям мин. Һәм борчылмый башлыйм.

⌄⌄⌄

18 яшемдә 35 яшьлек кешеләрне олы санаганым өчен гафу үтенәм.

⌄⌄⌄

Лилия шәраб бүлегеннән сөт сату бүлегенә күчкәч, сатып алучылар аңа никтер «матурым» дип эндәшми башладылар.

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 13584 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 352

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+